وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! *(Коръән, 3:103)*

6+

# ДИН вә Мәгыйшәт

№5 (238). МАЙ – 2015 / РӘҖӘП – ШӘГЪБАН – 1436

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

## БОЛГАРНЫ ЗИЯРӘТ КЫЛУ ШӘРИГАТЬКӘ ТУРЫ КИЛӘМЕ?

**1989 елда болгар бабаларыбызның рәсми рәвештә ислам динен кабул итүләренә 1100 ел тулуы тантаналы рәвештә билгеләп үтелде. Шул көннәрдән башлап Идел буе Болгар дәүләтенең башкаласы булган Болгар шәһәрен торгызу буенча бик зур эшләр башкарылды. Җәй көннәрендә Болгар җирләрен, сахабәләрнең җәсәдләре җирләнгән мөкатдәс урыннарны мөселманнар хәзер күпләп зиярәт итә.**


6-7 бит

Әйтергә кирәк, башта Болгар шәһәрен зиярәт кылучылар бик күп түгел иде. Ләкин бераз вакыт үткәч, аеруча бу чараны оештыруга мөселманнарның Үзәк диния нәзарәтеннән тыш Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм Бөтендөнья татар конгрессы да җәлеп ителә башлагач, зиярәт кылырга килгән мөселманнарның саны күпкә артты.

Билгеле ки, республикабызда хөрмәт күрсәтелергә һәм зиярәт кылынырга лаеклы булган мәртәбәле урыннар бик күп: бездә табигыйннар, тәбгы-табигыйннар, әүлияләр җирләнгән урыннар бар. Белгәнегезчә, табигыйннар – сахабәләрдән соң килгән, алардан өйрәнгән, аларның эшләрен дәвам иткән буын. Болгар чоры рухи мәдәнияте һәйкәлләре Биләрдә, Әтрәчтә (Тәтеш районына карый), Алабугада, Балык Бистәсе районында һәм башка урыннарда сакланып калган. Кызганыч, дәһрилекнең каһәрле елларында хакимият зиярәт кылуны тыя һәм әлеге йоланы үтәгән мөселманнарны эзәрлекли. Шуңа күрә безнең борынгы бу йолабыз һәм аны тиешенчә башкару тәртипләре онытыла төшкән. Күпләребез зиярәт кылуның әхлакый кагыйдәләре белән таныш түгел. Кайбер мөселманнарның зиярәт кылу тәртипләре буенча анык сораулары килеп туа. Бу язмада зиярәт кылу буенча килеп туган сорауларга җаваплар табарга тырышырбыз.

**(Ахыры 6-7 нче битләрдә.)**



5 бит

## «Рамазан – өммәтемнең ае»

**18 июньдә кояш баюга мөбарәк рамазан аена аяк басабыз. 17 июль – шәүвәл аеның беренче көнендә мөселманнар иң зур ике бәйрәмебезнең берсен – Ураза гаетен билгеләп үтәчәк**



11 бит

## “Белегез, батырлар Ватанга хезмәт итте!”

**ФРОНТОВИК ХАТИРӘЛӘРЕ**

НУЖНЫ ВОЛОНТЕРЫ !!!

СКОРО, ОЧЕНЬ СКОРО ДВА ВАЖНЫХ СОБЫТИЯ ГОДА!

1) 14 июня – «Болгар җыены»!

2) 26 июня – III Республиканский ифтар, Казань-арена!!!

Нужны волонтеры – молодежь с активной жизненной позицией!
Звоните и запишитесь!
Принимайте участие в благом деле ради получения довольства Всевышнего!!!
В подарок – футболки с нашим логотипом!

Телефон для записи:
Whats App +79270333142 (Айгуль)
+79274138494 (Алмаз)
https://vk.com/club93510129

## "ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ"

газетасын өйгә дә яздырып алырга була. Почта бүлекчәләренә мөрәҗәгать итегез.
Индекс – **16046**



## ГОЛӘМАЛАР ШУРАСЫНЫҢ САЙТЫ ӘЗЕРЛӘНӘ



**Казанның Тынычлык бистәсендә урнашкан Тынычлык мәчетендә мөфти хәзрәтләре катнашында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Голәмалар шурасының чираттагы утырышы үткәрелде. Җыелышны Голәмалар шурасының баш сәркатибе Рөстәм Нургалиев алып барды.**

Шура әгъзалары мәчеткә керү, анда булу тәртипләрен эшләү, рамазан аен уздыру, фитыр һәм фидия сәдакалары күләме хакында сөйләштеләр.

Моннан тыш Голәмалар шурасының сайтын эшләтеп җибәрү хакында фикер алыштылар. darulifta.tatar сайты озакламый интернет кырында барлыкка киләчәк. Әлеге сайтны ТР МДН әзерли. Аның аша Голәмалар шурасына һәркем үзен кызыксындырган, борчыган дини мәсьәләләр буенча сорауларын бирә алачак.

Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН:

## "ФӘТВАЛАР БЕЛЕМЛЕ БЕЛГЕЧ ТАРАФЫННАН ЧЫГАРЫЛЫРГА ТИЕШ"

**Ингушетиянең Магас шәһәрендә Ингушетия башлыгы Юныс бәк Евкуров катнашында "Диндәге уртачалык - тынычлыкка, күршеләр белән дуслыкка һәм алгарышка юлтүче юл" дип исемләнгән халыкара дини тәгълимат конференциясе узды.** Аның эшчәнлегендә ТР МДН рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты. Конференциягә шулай ук Әл-Карадаги җитәкләгән Бөтендөнья мөселман галимнәр берлеге әгъзалары, Россиядәге төрле конфессия вәкилләре, гарәп илләре илчеләре, Россия Президенты администрациясе вәкилләре чакырылган иде.

Конференциядә катнашучылар ислам галимнәре арасында хөкем сөргән фикер каршылыгы, төрле мәзһәбләрдә йолаларны үтәүдә аермалар, суфыйларның исламның таралышындагы роле кебек бик күп мәсьәләләр буенча фикер алыштылар.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең сәламләү сүзендә "Ингушетия - тынычлык урыны" фәтвасын кабул итүнең бу төбәк өчен зур әһәмияткә ия булуы хакында белдерде. Мөфти фикеренчә, хәзер дөрес һәм белемле белгеч тарафыннан чыгарылган фәтваларның булуы бик мөһим һәм элек-электән мөселман галимнәре фәтва чыгаруга зур җаваплылык белән караган. Чыгышы ахырында Камил хәзрәт Россиядә күренекле дин белгечләрен туплаган фәтвалар чыгару буенча бердәм мәйданчык оештыру инициативасы белән чыкты.

***

**Халыкара конференция кысаларында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Россия төбәкләренең кайбер мөселман дине лидерлары белән очрашу үткәрде.** Аерым алганда, ул Дагыстан мөфтие, шәех Әхмәд хаҗи Абдулаев белән очрашып, дини белем бирү мәсьәләләре турында сөйләште. "Җирдәге тынычлыкны мәгарифне үстереп һәм традицион диннәргә таянып эш иткәндә сакларга мөмкин. Шәкертләребез нәкъ үзебезнең илдә сыйфатлы дини белем алсын өчен тырышырга кирәк", - дип белдерде Татарстан мөфтие. Әхмәд хаҗи Абдулаев, үз чиратында, Дагыстан мөфтиятенең якын арадагы планнары белән уртаклашты. Ике яклы очрашу барышында алар фәтва кабул итү һәм төбәкләрдә дини китаплар чыгару мәсьәләләре буенча фикер алыштылар.

Моңардан тыш, Камил хәзрәт Сәмигуллин Кавказ мөселманнары лидеры шәйхелислам Аллаһшөкер Пашазадә һәм Ингушетия мөфтие Исса Хамхоев белән дә очрашты.

***

**Әлеге конференция кысаларында мөселман руханиларын тантаналы бүләкләү чарасы үтте.** Ингушетия Республикасы башлыгы Юныс бәк Евкуров Татарстан мөфтиен иҗтимагый-сәяси, дини һәм мәгариф өлкәләрендәге активлыгы өчен Ингушетия Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләде.

## ТАТАРСТАН МӨФТИЕ МАТУРИДИ ДИНИ МӘКТӘБЕНӘ БАГЫШЛАНГАН СИМПОЗИУМДА КАТНАШТЫ

**Төркестан шәһәрендә урнашкан Әхмәт Ясәви исемендәге Халыкара казах-төрек университеты матуриди дини мәктәбенә багышланган симпозиум уздырды. Әлеге "Матуридилыкның үткәне, хәзерге көне һәм киләчәге" дип аталган фәнни, дини чарада Татарстан мөфтие, ТР МДН рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм нәзарәтнең голәмалар шурасы әгъзасы, РИИ мөгаллиме Габдулла хәзрәт Әдһәмов катнашты. Симпозиумда Россия, Казахстан, Германия, Австралия, Болгария, Әзербәйҗан һәм Төрекмәнстанның дин белгечләре матуриди мәктәбенең гакыйдә буенча өйрәтүләре хакында сөйләштеләр.**

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт барлык катнашучыларны сәламләп, бөек галим Әбү Мансур әл-Матуриди калдырган рухи мирасны өйрәнү мөһимлеге хакында әйтте. Ул Идел буе мөселманнарының имам Матуриди мәктәбе, хәнәфи мәзһәбе өйрәтүләренә таянулары хакында сөйләде. "Мөселман дине белгече һәм татар тарихчысы Морад Рәмзи гарәп телендә язылган "Тәлфик әл әхбәр вә тәлких әл әсәр фивәкаи Казан вә Болгар вә мүлүкат татар" ("Казан, Болгар вакыйгалары һәм татар патшалары турында хәбәрләр вә истәлекләр җыентыгы") хезмәтенең авторы булараk билгеле. Гарәп, фарсы телләрен камил белүче, төпле гыйлем иясе Морад Рәмзи татар галимнәре хакында үзенең хезмәтендә язып калдырган. Ул аларның барысы да сөнни, матуриди һәм хәнәфи булулары һәм яңалык кертмәүләре хакында әйтә", - диде мөфти. Шулай ук ул бүгенге көндә Матуриди хезмәтләрен өйрәнү һәм аларны популярлаштыру мөһимлеген ассызыклады. Чөнки Урта Азия мөселманнары өчен генә түгел, Россия мөселманнары өчен дә матуриди мәктәбе өйрәтүләре традицион булып тора.

Имам әл-Матуриди үз вакытында гомуми рәвештә имам Әбү Хәнифә тарафыннан канунлаштырылган ислам тәгълиматы кануннарын формалаштыра һәм бер системага сала. Имам әл-Матуриди тарафыннан формалаштырылган иман шарты изге Коръәни Кәрим һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Сөннәтенә нигезләнгән. Бөек татар галиме Шиһабетдин Мәрҗани әйткән: "... әл-Матуриди Мавәраннәһернең баш Хәнәфиләреннән берсе, үз заманының иң күренекле имамнарының берсе, сахабәләр һәм Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең табигыйннары арасыннан булган изге бабаларыбызның кануннарына тугры булган, һәм Әбү Хәнифә һәм аның әүвәлге дәвамчылары тәгълиматын тирәнтен аңлатып, мисаллар һәм дәлилләр белән халыкка җиткергән".

## РОССИЯ ДИН БЕЛГЕЧЛӘРЕ ИСЛАМ МӘГАРИФЕ ХАКЫНДА ФИКЕР АЛЫШТЫ

**Россия ислам институтында күп сандагы мәртәбәле кунаклар, дин галимнәре катнашында Ислам мәгарифе советы утырышы үткәрелде. Сөйләшүгә барлыгы 32 югары һәм урта белем бирү уку йорты җитәкчесе, төрле төбәк мөфтиләре җыелды. Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Ә.Сәфәров, Россия Президентының Эчке сәясәт буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары М.Белоусов, Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә ярдәм итү фонды җитәкчесе А.Жданов һәм башкалар катнашты.**

Утырышта катнашучыларны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин сәламләде. "Ислам мәгарифе – Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте аеруча игътибар бирә торган өлкә. Ислам ул – гыйлемнәр дине. Аллаһы Тәгаләдән иңдерелгән иң тәүге аятьтә үк безгә укырга кушылган: "Сине юктан бар иткән Раббының исеме белән укый башла" (Коръән, 96-1). Исламда галимнәр зур мәртәбәгә ия. Аллаһы Тәгалә Коръәндә аларны Үзе югары дәрәҗәләргә күтәрә: "Сездән иман китереп итагать иткән вә белем иясе булган мөэминнәрне Аллаһ дәрәҗәләргә күтәрер, Аллаһ сезнең кылган эшләрегездән хәбәрдар" (Коръән, 58-11). "Иң зур дәрәҗә ул – гыйлем дәрәҗәсе", - диелгән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә", - дип чыгышын башлады Камил хәзрәт Сәмигуллин. "Әгәр дә узган елларны искә төшерсәк, 90 елларда күбрәк дини уку йортларын ачарга, төзергә тырыштык. Хәзер исә ислам мәгарифе сыйфатын күтәрү өчен шактый эшләр башкарыла. Шуның өчен дә без ике ел элек дәреслекләр, программалар әзерләү белән шөгыльләнүче Уку-укыту-методик берләшмәсен оештырдык. Татарстан мөфтиятенең махсус комиссиясе хәнәфи мәзһәбенең бөтен ислам дөньясына таралган һәм инкыйлабка кадәр татар мәдрәсәләрендә укытылган классик әсбапләр исемлеген барлады. Хәзерге вакытта бу китапларны кабаттан нәзарәтнең "Хузур" нәшрият йорты нәшер итә", - диде ул.



Мөфти хәзрәтләре Мәрҗани, Утыз Имәни, Ризаэддин Фәхретдин кебек олуг татар дин галимнәренең зур рухи мирасын өйрәнү, белү мөһимлеген ассызыклады. Россиянең бәйсез ислам эксперт советын булдыру кирәклеге хакында сөйләде. Шулай ук мөфтият тарафыннан, КФУ һәм РИИ белән берлектә имамнарның, мөгаллимнәрнең гыйлемен күтәрү максатыннан күп сандагы курслар оештырылуы хакында әйтте.

Утырышта Ислам мәгарифе советы җитәкчесе, мөфти урынбасары, РИИ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин Болгар ислам академиясен оештыру хакында җиткерде. Урта мөселман уку йортлары эшчәнлегенә, укуукыту программаларын әзерләүгә кагылышлы фикерләре белән уртаклашты.

***Шулай ук җыелышта советның http://www.islam-obr.ru/ сайты тәкъдим ителде.***

# КУКМАРА МӘДРӘСӘСЕНДӘ – ЧЫГАРЫЛЫШ



**Быел Кукмара мәдрәсәсенең һөнәри бүлеген 41 шәкерт тәмамлады: ир-егетләр 21 кеше, хатын-кызлар исә - 20. Алар барысы да 4 еллык уку-укыту программасын үзләштереп, чыгарылыш имтиханнарын тапшырдылар һәм диплом эшләрен яклады-лар. Ир-егетләргә "Имам-хатыйб", ә хатын-кызларга "Ислам нигезләре мөгаллимәсе" квалификациясе бирелүен раслый торган дипломнар тапшырылды. Алар арасында инде хәзер дин өлкәсендә хезмәт итүчеләр - имамнар һәм мәхәлләләрендә дин белеме бирүче мөгаллимнәр бар.**

Һөнәри бүлектән тыш, быел мәдрәсәнең башлангыч бүлеген тәмамлаучылар да булды. Алар арсында өлкәннәр дә, якшәмбе мәктәбендә белем алган балалар да бар. Башлангыч бүлекне 23 ир-егет һәм 50 хатын-кыз тәмамлады (шулар арасында 24 яшүсмер).

Быелгы чыгарылышка багышланган тантанада Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Коръән бүлеге мөдире Илнур Хәйруллин катнашты. "Мәдрәсәдә укуны тәмамлап диплом алуга ирешү - бер яктан караганда сөенечле вакыйга, икенче яктан исә бик моңсу да, - диде Илнур хәзрәт, - чөнки бер хәдистә "Гыйлем алучы кеше өчен барлык мәхлукат, хәтта судагы балаклар да дога кылыр, ул кешене зикер итәр" дигән хәбәр килә, гыйлем алудан туктадың икән, барча мәхлукат сине зикер кылудан туктый кебек... Шуңа күрә гомер азагына кадәр бик тә файдалы, мавыктыргыч һәм нурлы гыйлем юлыннан һич тә читләшмәгез, гыйлем алуны беркайчан да туктатмагыз", - дип мөрәҗәгать итте шәкертләргә.

Тантанага җыелган шәкертләр һәм мөгаллимнәр алдында шулай ук Кукмара Үзәк мәчете имамы Әхтәм хәзрәт Мөбаракшин, район имаммөхтәсибе Зиннур хәзрәт Сәмигуллиннар да вәгазь-нәсыйхәтләре белән чыгыш ясады. Алар дини гыйлем алуның фазыйләтләрен искәртеп, шәкертләргә белгәннәре белән гамәл кылырга һәм алга таба тагын да зуррак максатлар куярга киңәш иттеләр. Әхтәм хәзрәт: "Белмәгәнеңне белү - гыйлемнең яртысы", - дип билгеләп үтсә, Зиннур хәзрәт: "Гыйлемнең башы ул - Аллаһны тану, ә гыйлемнең ахыры ул - һәрбер хәлне Аллаһка кайтару", - дигән хикмәт иярләренең фикерен китерде.

Чыгарылыш шәкертләренең һәммәсенә дә Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан ярдәм итеп бирелгән китаплар һәм вәгазь дискылары тапшырылды. Шул уңайдан Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга һәм Диния нәзарәтенең Аппарат җитәкчесе Ришат әфәнде Хәмидуллинга мәдрәсә җитәкчелеге исеменнән олы рәхмәтебезне белдерәбез. Шактый кыйммәтле бүләкләрен мәдрәсә коллективына тапшырган Кукмара "Металл савыт-сабалар заводы" оешмасы генераль директоры Азат Ясави улы Заһидуллин адресына да иң изге теләкләребезне, җылы рәхмәт сүзләребезне юллыйбыз. Һәрбарчагызның да эшегез уң булсын, Аллаһ Раббыбыз ярдәменнән ташламасын.

Өйлә намазы укылганнан соң чыгарылышка багышланган чара укучылар оештырган мул табын алдында дәвам итте. Мәҗлеснең әлеге өлешендә дә шәкертләр мөгаллимнәргә ихластан олы рәхмәтләрен җиткерделәр, үзләре язган шигырьләрен укып, максатка ирешү шатлыгын һәм мәдрәсәдән аерылу белән бәйле моң-сагышлы хисләрне чагылдыручы уй-фикерләре белән уртаклаштылар. Мөгаллимнәр исә шәкертләргә тормыш юлын Аллаһ кануннарына ныклап тотынып, дини уку йорты - мәдрәсә тәмамлаган шәкерт дәрәҗәсенә тугрылыклы һәм лаеклы булып узарга, Аллаһы Тәгалә мөэминнәргә әзерләгән гаҗәеп җәннәтендә дә очрашырга насыйп булсын дигән изге теләкләрен җиткерделәр.

# ХАҖ СӘФӘРЕНӘ ӘЗЕРЛЕК БАРА

**Быел хаҗ сәфәре сентябрь урталарында башланыр дип көтелә. 2015 елда изге сәфәргә җыенучылар өчен виза алырга, документлар җыярга вакыт күп калмады. Шуңа күрә бу ниятне тормышка ашыру өчен әзерлек эшләрен тизләтү сорала.**

Хаҗиларга куелган таләпләр:

- чит ил паспортының яңа төре. Гамәлдән чыгу вакыты 6 айдан да ким булмаска тиеш;
- Россия паспорты копиясе;
- участок табибыннан сәламәтлек хакында белешмәләр кирәк, дифтериягә, менингитка каршы прививкалар ясалган булырга тиеш;
- 45 яшькә кадәрге хатын-кызны якын туганнарыннан булган ир-ат (25 яшьтән дә яшьрәк булмаган) озата бара. Туганлыкны раслаучы документ кирәк;
- бергә баручы ир белән хатынның никах таныклыгы булуы сорала;
- 2 фотография - 4х6 (ак фонда төсле. Хатын-кызларга яулык белән, ир-атларга баш киемсез).

# КАЗАНДА "ТҮБӘТӘЙ" МИЛЛИ, ХӘЛӘЛ КАФЕЛАР ЧЕЛТӘРЕ АЧЫЛА




**Бер төркем инициативалы егетләр июнь аенда Казанда "Түбәтәй" дигән беренче татар фастфуд кафесын ачарга булган. Бер ел эчендә алар Казанда 15 урын, Татарстанның башка шәһәрләрендә тагын 10 урын ачарга телиләр. Проектның планлаштырылган айлык акча әйләнеше – 25 млн сум. Киләчәктә егетләр франшиза системасы аша башка илләрдә дә "ТҮБӘТӘЙЛӘР" барлыкка киләчәк, дип өметләнә.**

"Түбәтәй"нең үзенчәлекләре арасында ризыкны заманча уңайлы савытларда тарату, балалар өчен махсус меню булдыру, савытларда татар әдипләренең шигырь юллары һәм өзекләр язу кебек идеяләр бар. Хезмәткәрләр татар милли киемнәрендә булачак, өч телдә сөйләшәчәкләр, татар кунакчыллыгы һәм югары әхлак традицияләренә күрә хезмәт күрсәтәчәкләр.

Азатлык радиосы идея авторы Солтан Савинга берничә сорау белән мөрәҗәгать иткән.

**- Солтан, бу кафелар челтәре идеясе кайдан барлыкка килде?**

- Бу фикер 5 ел элек, мин әле студент булган чакта туган иде. Дусларым белән ашап алырга теләгән идек. Тиз ашап алыр өчен хәләл урын эзләдек, тик таба алмадык. Таба алмагач, Макдоналдска барырга туры килде.

Кәеф бик төшкән иде. Нигә бездә үзебезнең милли фастфудыбыз юк? Нигә без тәмле татар брендын оештыра алмыйбыз соң? Аны бит бөтен Казан, Татарстан һәм Русия халкы кулланыр иде. Бу сораулар мине "Түбәтәй" проектын уйлап чыгаруга этәрде дә.

**- Бу кафеларның хуҗасы кем булачак? Гомумән, кемнәр белән ачасыз?**

- Авторларының берсе мин булып чыгам инде. Болай, без өчәү ачабыз: мин, Азат Нәҗметдинов һәм Айнур Камалиев.

**- Ничә кафе ачарга җыенасыз?**

- Аллаһ боерса, бу җәйдә Казанда 6 урын ачарга уйлыйбыз, ләкин, бездә әле башка "Түбәтәй" проектлары да бар, алар әлегә сер, үзегез күрерсез. Башка шәһәрләр турында әйтә алмыйм, чөнки франшиза буларак оештырырга уйлыйбыз. Татарстан, Россия шәһәрләрендә һәм башка илләрдә "Түбәтәй"ләрне күрербез, Аллаһ боерса.

**- Беренче ноктагыз кайда ачылачак соң?**

- Июнь аенда Казан үзәгендә булачак ул. Төгәл урыны әлегә юк.

Проект авторлары фикеренчә, "Түбәтәй" милли ашларның заманча вариантта торгызылуына тәэсир итәчәк. Матур милли дизайн ярдәмендә алар үз кафеларының Казанның туристларны җәлеп итә торган урынына әйләнәчәк дип уйлый.

Бәягә килгәндә, оештыручылар клиентлар өчен аны мөмкин кадәр түбән итәргә тели. Мәсәлән, 150-180 сумга туристлар өчен комбо-меню алырга мөмкин булачак: кечкенә өчпочмак, гөбәдия, өлеш, эчемлек һәм сувенир. Сүз уңаеннан, менюга шулай ук чит ил кешеләренә яхшы таныш булган гамбургерлар да керәчәк.

Хәзерге вакытта егетләр Вконтакте сайтында блог алып баралар. Кафе ачуның һәр адымын анда тасвирлыйлар. Татар фастфуды ачылышының нинди этапта булуын һәр теләгән кеше карый ала.

# КҮҢЕЛЛЕ ДӘ, ФАЙДАЛЫ ДА БУЛСЫН!

**Җәйге каникулларга да санаулы гына көннәр калып бара. Ата-аналар балаларының кайда, ничек ял итәчәкләрен планлаштырып та куйганнардыр инде. Ә без сезгә тагын бер вариант тәкъдим итәбез. Балаларыбыз күңелле дә, файдалы да ял итсен, динебез турында мәгълүмат алсын, әдәп-әхлакка өйрәнсен дисәгез, каникулның беренче көннәреннән үк түбәндәге мәчетләрнең балалар мәйданчыкларына рәхим итегез!**

| | |
|---|---|
| АЗНАКАЙ | Ак мәчет |
| АКСУБАЙ | җамигъ мәчет<br>Иске Ибрай<br>Яңа Ибрай |
| АКТАНЫШ | җамигъ мәчет |
| АЛЕКСЕЕВСК | җамигъ мәчет |
| ӘЛМӘТ | җамигъ мәчет |
| БАУЛЫ | Кызылъяр мәчете<br>Хәнсуәр мәчете |
| БИЕКТАУ | җамигъ мәчет |
| ЗӘЙ | җамигъ мәчет |
| КАЗАН | Гаилә мәчете<br>Апанай мәчете |

| | |
|---|---|
| БӨГЕЛМӘ | җамигъ мәчет |
| ЛАЕШ | җамигъ мәчет |
| МАМАДЫШ | мәдрәсәдә |
| МИНЗӘЛӘ | җамигъ мәчет |
| НУРЛАТ | авыл мәчетләре |
| САРМАН | җамигъ мәчет |
| СПАС | Ак мәчет |
| ЧАЛЛЫ | Нур-Ихлас мәчете<br>Рамазан мәчете<br>Туфан мәчете |
| ТУКАЙ | Теләнче-Тамак мәчете |

# БАЛАЛАРНЫ НАМАЗ УКЫРГА ӨЙРӘТҮ - АТА-АНАНЫҢ ТӨП БУРЫЧЛАРЫНЫҢ БЕРСЕ

Татарстан Республикасы мөфтие
Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

**Рәхимле һәм Рәхмәтле Аллаһ исеме белән. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булса иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сәламнәребез барып ирешсә иде.**



Балалар 7 яшькә җиткәч, намаз укый башларга тиеш. Чөнки Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вә сәлләм): "Балаларыгыз 7 яшькә җиткәч, аларга намаз укырга кушыгыз", - дигән. Димәк, мөселман кеше үзе 5 вакыт намаз укыган кебек балаларын да намаз укырга өйрәтергә тиеш. Чөнки бу яшьтә намаз укырга гадәтләнгән бала, үскәч аны төшенеп һәм дөрес итеп укыячак. Балаларны намаз укырга өйрәтү - ата-ананың төп бурычларының берсе.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай ди: **"Ий, Мөхәммәд галәйһиссәләм! Өй әһелеңне вә өммәтеңне намаз укырга боер, ярлы булсаң да намаз уку, намазга өйрәтү һәм намазга боеру мәшәкатьләренә сабыр ит..."** ***("Та һа" сүрәсе, 132 нче аять).*** Бу аять иңдерелгәч, Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) алты ай дәвамында кызы Фатыйманы (радыйаллаһу ганһә) үзе иртәнге намазга уята торган була. Кызы Галидә (радыйаллаһу ганһү) кияүдә булу сәбәпле, ул аларның өйләренә кермичә: "Әс-сәлах, әс-сәлах", - дип кычкыра, бу "намаз, намаз" дигәнне аңлата. Алты ай буе шулай дәвам итә. Бу үрнәктән без намазның нинди мөһим булуын күрәбез. Гали (радыйаллаһу ганһү) һәм Фатыйма (радыйаллаһу ганһә) намазларын калдыра алалармы? Әлбәттә, юк. Аллаһы Тәгалә Илчесе (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) шул рәвешле өммәтенә үрнәк күрсәтә. Бу мисалда без аталарның балаларын намаз кылырга өйрәтергә бурычлы булуларын күрәбез.

Галинең (радыйаллаһу ганһү) намазын ничек кылуын карагыз. Бер сугышта аның аягына ук кадала. Укның очлыгы аяк сөягенә керә. Табибны чакырып китерәләр. Табиб: "Авыртуны тоймас өчен, аңны миңгерәйтә торган дару эчәргә кирәк, шул очракта гына без укны тартып чыгара алачакбыз. Башкача сез авыртуга чыдый алмаячаксыз", - ди. Гали (радыйаллаһу ганһү) болай дип җавап кайтара: "Бернинди дә дару кирәкми. Тиздән намаз вакыты җитәчәк. Мин намаз укый башлагач тартып чыгарыгыз".

Намаз вакыты җитеп, Гали (радыйаллаһу ганһү) намаз укый башлагач, табиб операциягә керешә һәм ук очлыгын аяктан тартып чыгара. Намазны тәмамлагач, Гали (радыйаллаһу ганһү) табибтан: "Укны тартып чыгардыңмы?"- дип сорый. Табиб тартып чыгаруы турында әйтә. Гали (радыйаллаһу ганһү): "Мин бернәрсә дә сизмәдем", - ди. Йә Аллаһ! Безгә дә намазны шундый халәттә укырга насыйп ит.

Намаз - Аллаһның үзе белән сөйләшү. Намаз укый башлагач, мөселман кеше Аллаһы Тәгалә каршына барып баса.

Икенче бөек сахабә Гомәр бине әл-Хаттаб (радыйаллаһу ганһү) белән булган хәлне искә төшерик. Хөрмәтле Гомәр (радыйаллаһу ганһү) намаз кылу өчен мәчеткә иртәрәк чыгып китә торган булган. Бервакыт ул кечкенә генә ир баланың мәчеткә таба йөгерүен күрә һәм аның ни сәбәпле ашыгуын сорый. Бала азанга кадәр тәһарәт алырга өлгерергә теләве турында әйтә. Гомәр (радыйаллаһу ганһү): "Син бит әле кечкенә, сиңа намаз уку мәҗбүри түгел", - ди. Моңа каршы бала болай дип җавап кайтара: "Мондый гамәлләрдә кечкенәләр белән олылар арасында аерма бармыни? Кичә миннән дә кечерәк бала үлеп китте".

Бу мисал безнең барыбызга да зур үрнәк булырга тиеш. Намаз мәҗбүри булу яшенә җитмәгән кечкенә мөселман баласы намазга ашыга. Балигъ булган мөселман бигрәк тә намазларын калдырмаска тиеш. Ул үзен "соңрак укырмын, иртәгә укырмын" дигән сүзләр белән тынычландырмасын. Кайберәүләр: "Мин әле яшь, картайгач, пенсиягә чыккач, намаз укый башлармын. 50, 60 тулгач, намазга керешермен әле", - дип уйлый. Бу ялгыш фикер. Кеше күпме яшәячәген белми - бер көнме, бер елмы, әллә йөз елмы. Билгеле бер яшькә җитәчәгенә контракты юк. Намазны калдырырга ярамый. Калдырган намазларыгызны тулыландырыгыз.

Аллаһы Тәгалә безнең гөнаһларыбызны гафу итсә иде. Әмин.

# Һәркем үз гамәлләре өчен җавап тотачак

**"Аллаһ үзенең эшләгән эшләреннән соралмас, әмма кешеләр эшләгән эшләреннән соралырлар" ("Пәйгамбәрләр" сүрәсе, 23 нче аять).**



Ислам дине мөселманнарны үз гамәлләре өчен җавап тотарга өйрәтеп тәрбияли. Болай тәрбияләнгән кеше фәрештә дәрәҗәсенә җитә һәм өскәрәк тә күтәрелә ала. Кешенең яралтылуының асылы шунда билгеләнә. Һәр кеше кечкенә һәм зур гамәлләре өчен галәмнәрнең Хуҗасы алдында җавап тотачак. "Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылган булса, аның җәзасын күрер. Вә берәү тузан бөртеге хәтле гөнаһ эшләсә, аның җәзасын күрер" ("Зүлзилят (Җир селкенмәк)" сүрәсе, 7,8 нче аятьләр).

Кешенең кем булуы (җитәкчеме әллә хезмәтчеме, баймы әллә ярлымы) мөһим түгел, ул барыбер гамәлләре өчен Аллаһы Тәгалә каршында җавап тотачак. Аллаһы Тәгалә каршында барыбыз да бертигез, туганда һәр кеше чиста һәм гөнаһсыз булып туа. Бу турыда безгә Коръәни Кәримнең түбәндәге аяте әйтә: "Адәм балаларын ничә җәһәттән башкаларга караганда өстен вә хөрмәтле кылдык..." ("Бәни Исраил" сүрәсе, 70 нче аять).

Җаннарын саклаган, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршында җавап тотачаклары турында белгән һәм аңлаган кешеләр бәхетле. Аларның гамәлләре һәм кешеләргә хезмәт итүләре бары тик Аллаһы Тәгалә хакына һәм Аның ризалыгына ирешү өчен. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай ди: "...сезнең Аллаһ хозурында хөрмәтлерәгегез Аллаһтан куркып, гөнаһлардан сакланучыгыздыр" ("Хуҗурат" сүрәсе, 13 нче аять). Кешенең иң яхшы сыйфаты - барлык кылган гамәлләре өчен Аллаһы Тәгалә каршында җавап тотачагын аңлау. Бу сыйфатның бик нечкә ягы бар. Нәкъ менә бу сыйфат Әбү Хәнифәнең атасын белмичә ашаган алма өчен өч ел хезмәт итәргә мәҗбүр итә.

Яшь чагында Имам Әгъзамның әтисе Сабит елга ярында тәһарәт ала. Тәһарәт алып бетергәч, догалар укыганда ул суда агып килгән аклы-кызыллы сусыл алманы күрә һәм тотып алып кабып карый. Бер мизгелдән аңына килеп, ул болай ди: "Мин нәрсә эшләдем! Бу алманың хуҗасы бардыр бит. Хуҗасының рөхсәтеннән башка мин ничек алманы ашап карый алдым соң?" Бераздан Сабит алма агып килгән елга яры буйлап китә һәм нәкъ шундый алмалар үскән алма бакчасын күрә. Алманың бу бакчадан булуын аңлап, бакча хуҗасын эзли башлый. Хуҗаны тапкач, ул аңа болай дип мөрәҗәгать итә:

- Хуҗа! Минемчә, бу алма елгага сезнең бакчагыздан төшкән. Мин аны, анымоны уйламыйча, ашап карадым. Шул сәбәпле мин сездән гафу үтенергә һәм алманың хагын түләргә дип килдем.

Моңа каршы бакча хуҗасы:

- Юк, мин сине гафу итә алмыйм. Син нигә минем алмамны минем рөхсәтемнән башка ашап карадың? - ди.

Сабит:

- Ий, Хуҗа! Гафу итүеңне үтенәм! Мин моның өчен ни рәвешле һәм нәрсә белән түли алам?

Бакча хуҗасы:

- Син минем белән бергә бу бакчада өч ел эшләргә тиеш, шуннан соң сине гафу итү турында уйлап карармын.

Имам Әгъзамның атасы Сабит бу шартларга риза була. Шулай итеп, чит кеше алмасын бер тапкыр кабып карау өч ел хезмәт итүнең сәбәбе була.

Сабит бакчада эшли башлый. Өч ел тулгач, ул бакча хуҗасы янына килеп, болай ди:

- Хуҗа, бүген өч еллык хезмәтемнең соңгы көне, мине гафу итеп, җибәрүегезне үтенәм.

Бакча хуҗасы:

- Бер шартым бар! Мин, өч ел узгач, сине гафу итәргәме-юкмы - уйлап карармын дигән идем. Шартымны үтәсәң гафу итәрмен. Минем кызым бар. Аның күзләре күрми, колаклары ишетми, кулсыз-аяксыз. Аңа өйләнсәң һәм тәрбиягә алсаң гына, мин сине афу итәчәкмен.

Сабит риза була. Алар кунаклар чакырып, туй үткәрәләр. Сабит кәләше янына кереп, сау-сәламәт кызны күргәч, үз күзләренә үзе ышанмый, нindидер хата килеп чыккан яки кемдер шаярта дип уйлый. Кызның әтисе янына килә дә болай ди:

- Хуҗа! Сез бит кызыгызның кулсыз, аяксыз, сукыр һәм саңгырау булуы турында әйттегез. Ләкин мин сау-сәламәт һәм матур кызны күрдем.

Кызның әтисе:

- Әйе, улым, хәзер игътибар белән тыңла. Минем кызым сукыр һәм саңгырау, чөнки ул тыелганга карамый һәм тыелганны ишетми. Аның куллары һәм аяклары юк, чөнки ул тыелганга таба бармый һәм тыелганны кулына алмый.

**(Ахыры 5 нче биттә).**

# Һәркем үз гамәлләре өчен җавап тотачак

**(Ахыры. Башы 4 нче биттә).**

Мин кызыма тулы иманлы кешене эзләдем. Үзен, кызымны, балаларын тыелганнан саклар-лык, ә йөрәге синеке кебек Аллаһы Тәгаләдән курку белән тулган кешене эзләдем. Аллаһы Тәгалә сине миңа җибәрде. Алманы кабып караган өчен гафу итүемне сорагач, мин синең тулы иманлы, намуслы кеше булуыңны аңладым һәм сынап карарга булдым. Өч ел дәвамында сынадым һәм синдә кызым өчен эзләгән кешене күрдем. Озак һәм бәхетле яшәгез!

Шулай итеп, Имам Әгъзам Әбү Ханифә шундый ата-анадан туа. Бала чагында, өч көндә Коръәни Кәримне укып чыккач, ул өенә кайтып, әнисенә мөрәҗәгать итә: "Әнием, мин бүген Коръәни Кәримне укып бетердем. Мин аны өч көндә укып чыктым". Әйтеп бетергәч, әнисен кочаклап ала. Әнисе аңа: "Улым, Әтиең яшь чагында теге алманы кабып карамаган булса, син аны бер көндә укып бетерә алыр идең", - ди.

Игътибар итегез: кеше рөхсәтсез алманы кабып караган өчен өч ел хезмәт итә, ә алга таба бу Имам Әгъзамның Коръәнне ике көнгә соңрак укып бетерүенә сәбәп була. Хәзерге мөселманнарның кайберләре кызларын югары хезмәт урыны, акчасы, йорты һәм машинасы булса, теләсә кемгә кияүгә бирергә әзер. Соңыннан алар: "Кызыбыз начар кеше кулына эләкте. Ул аны хөрмәт итми", - диләр. Монда алар үзләре гаепле түгел микән? Әлбәттә, шулай. Бакча хуҗасы иманлы, Аллаһы Тәгаләдән куркучы кеше урынына кызын машинасы, фатиры һәм акчасы булган кешегә кияүгә бирер идеме?! Ислам динендә намус һәм кыйммәтләр түбәндәге сүрәдә күрсәтелә: "...сезнең Аллаһ хозурында хөрмәтлерәгегез Аллаһтан куркып, гөнаһлардан сакланучыгыздыр" (Хуҗурат" сүрәсе, 13 нче аять). Иманлы кеше Аллаһы Тәгалә нәрсәне рөхсәт иткәнне һәм нәрсәне тыйганны һәрвакыт белә.

Хөрмәтле мөселман кардәшләр! Кыямәт көнендә җавап тотачак гамәлләрегез турында уйланыгыз. Һәр гамәлегез Аллаһы Тәгалә каршына кителәчәк, шуңа күрә гадел хөкемгә әзерләнегез. Кылган начар гамәлләрегезне күрмәсләр дип уйламагыз. Һичшиксез, һәркем гамәлләре өчен җавап тотачак.

# "Рамазан – өммәтемнем ае"

Тиздән бөтен айларның солтаны - изге рамазан аена аяк басабыз. Рамазан - барлык гөнаһлардан пакьләнү, күңелләрне сафландыру, аны күркәм сыйфатлар белән бизәкләү ае. Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай ди: **"Өммәтем гади айда кылган бер яхшы гамәл өчен бер савап ала, әмма рамазанда исә Аллаһ бер яхшы гамәл өчен җиде йөзгә хәтле һәм аннан да күбрәк әҗер бирә. Фарыз гыйбадәтләренең берсе өчен башка айларда кылган җитмеш фарызның савабын, нәфелләре өчен исә башка айларда кылган фарызның савабын бирә".**

Изге айның өстенлекләре Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм өммәте өчен махсус бирелгән. Шуңа күрә Мөхәммәд галәйһиссәлам бер хәдистә: "Рамазан - өммәтемнең ае", - дигән.

Бервакыт Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләдән: "Йә, Раббым, Синең миннән дә якынрак бәндәләрең бармы?", - дип сораган. Аллаһы Тәгалә: "Әйе, алар хәбибем Мөхәммәд галәйһиссәлам өммәтедер", - дигән. Шунда Муса галәйһиссәлам: "Мин синең белән Тур тавында сөйләштем, ә алар сиңа ничек якын булды соң?"- дигән. Аллаһы Тәгалә әйткән: "Әй, Муса, син минем белән Тур тавында сөйләшкәндә арабызда пәрдә бар иде. Мөхәммәд галәйһиссәламнең өммәте уразада иреннәре кибеп, ифтар вакытында куллары догага күтәргәндә күк белән җир арасындагы пәрдә күтәрелә. Догаларын кабул итәм, чөнки бу мизгелдә алар Минем белән пәрдәсез сөйләшә", - дигән. Шунда Муса галәйһиссәламнең: "Йә, Раббым, шул рамазан-шәриф уразасын минем өммәтемә дә бирче", - дигән соравына җавап итеп Аллаһы Тәгалә: "Бу ураза хәбибем Мөхәммәд галәйһиссәлам өммәтенә генә хастыр", – дип әйткән.

Бер хәдис-шәрифтә болай диелә: **"Дөреслектә җәннәттә бер ишек бар. Ул Әр-Раян дип атала. Кыямәт көнендә ул ишектән ураза тотучылар гына керер. Алардан башка һичкем кермәс. "Кайда ураза тотучылар?" - дип әйтелер. Шулвакыт ураза тотучылар торып басар. Алар җәннәткә кергәч, ишек ябылыр һәм беркем дә ул ишектән кермәс"** *(Бохари, Мөслим).*

# Намаз

**Исламның икенче төп баганасы булып намаз уку тора. Балигъ булган һәр аңлы мөселман намаз укырга тиеш. Бу хакта Коръәни Кәримдә язылган, ә аның башкарылу тәртибен безгә Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләм өйрәтеп калдырган.**

Мөселманнар мәҗбүри намазны тәүлегенә биш тапкыр: таң алдыннан, өйләдә, өйләдән соң, кояш баегач һәм төнлә үтиләр. Намазны мәчеттә һәм өйдә, эш урынында яки укыган җирдә, урамда, ягъни теләсә кайсы чиста җирдә укырга мөмкин. Намаз ялгыз да, җәмәгать белән дә укыла.

Намаз диннең мөһим таләбе һәм нигезе булып тора, иманлы кеше белән Аллаһы Тәгалә арасында элемтә барлыкка китерә. Шуңа күрә аны төрле шартларда: авырганда да, сугышта яки сәфәрдә булганда да үтәү мәҗбүри. Намазны калдырырга ярамый. Ниндидер сәбәпләр аркасында мөселман намазны вакытында үтәргә өлгермичә калса, ул намазны мөмкинлеге тугач та каза кылырга кирәк. Намаз уку өчен басып тора алмаган кеше - утырып, утыра алмаган кеше ятып укырга да мөмкин. Сәфәрдәге кеше намазны кыскартып укый ала.

Гамәли яктан караганда, намаз - ул сүзләр һәм хәрәкәтләр кушылмасы. Намаз укый башлаганчы, мөселман тәһарәт алырга тиеш. Шуннан ул Кагъбәгә юнәлеп баса, башкарасы намазына күңелен салып, Аллаһы Тәгалә хакы-хөрмәте өчен намаз үтәргә ният кыла, кулларын күтәрә һәм "Аллаһу Әкбәр" (Аллаһы Тәгалә бөекләрдәнбөек) дип әйтә. Намаз эчендә Коръәннән сүрәләр, Аллаһыны искә алу сүзләре (зикерләр) һәм догалар укыла. Намаз "Әссәләәәмү галәйкүм вә рахмәтуллаһ" (Аллаһы Тәгаләнең сезгә сәламе һәм рәхмәте булсын!) сүзләре белән уңга һәм сулга сәлам бирелеп тәмамлана.

Намазга балачактан ук өйрәтергә кирәк. Бала аны кече яшьтән үк тормышының аерылгысыз бер өлеше булараk кабул итәргә тиеш. Әти-әнисенең намаз укуын күрергә тиеш, аннан бала үзе дә аларның хәрәкәтләрен кабатлый башлый. Мондый күренешне теләсә кайсы мөселман гаиләсендә күзәтергә мөмкин. Балалар ата-ананың гамәлләрен кабатлый торган була. Көнгә биш тапкыр намаз укучы әлкәннәрнең хәрәкәтләрен бала берничек тә күрми кала алмый. Үзләре үк намазлык җәеп, азан сүзләрен кабатлыйлар һәм намаз укый башлыйлар. 7 яшенә бала барлык намазларны да башкара белергә тиеш һәм аны моңа даими өндәп торырга кирәк.



## ҖОМГА ИРТӘСЕНДӘ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

Аллаһ Расүле саллэллаһу галәйһи вә сәлләм җомга иртәләрендә әлеге доганы укый торган булган: "Әстәгъфируллаһә ллэзии ләәә иләәһә иллэә һүүә-ль хәййү-ль каййүүмә үә әтүүб иләйһи" (мәгънәсе: "Аннан башка һичбер илаһ булмаган тере һәм даими бар булган Аллаһы Тәгаләдән гафу сорыйм һәм тәүбә итәм" ("Әл-әзкәр": 80).

# Ураза

***Исламда ураза тоту көн яктысында, ягъни кояш чыкканнан алып кояш баеганчыга кадәр ашау-эчүдән, җенси якынлык кылудан тыелып торудан гыйбарәт.***

Мөселманнарга ураза тоту Коръәни Кәримдә кушылган. Әхлакый яктан караганда, ураза кешене гөнаһлардан арынырга, гәүдә ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән тыелып тору нәтиҗәсендә үз игътибарын дини бурычларын үтәүгә юнәлдерергә, уйланырга һәм хәерле гамәлләр кылырга, ашау-эчүгә мохтаҗлыклары булмаган һәм һәрвакыт Аллаһы Тәгаләгә табынып торган фәрештәләргә охшарга мөмкинлек бирә.

Уразаны җиңел үткәрсә, иманлы кеше Аллаһы Тәгаләгә шөкер итә. Әгәр уразасы авырлыклар белән уза торган булса, мөселман үзенең сабырлыгы өчен Аллаһы Тәгалә аның гөнаһларын кичерер һәм иманын ныгытыр дип өметләнә.

Кешеләрнең күбесенә ураза ачлык һәм сусаудан башка берни дә бирми, дип кисәткән Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләм. Шуңа күрә мөселман ашауэчүдән формаль рәвештә тыелу белән генә чикләнмәскә тиеш. Үзенең мөмкинлекләренә карап, һәркемгә уразаның әчке тирән мәгънәсенә дә игътибар итәргә кирәк. Күзләрне - тыелган нәрсәләргә караудан, телне - буш, мәгънәсез, яман сүзләр, гайбәт сөйләшүдән, бәхәсләрдән, колакларны - башкаларның гайбәт сүзләрен һәм сүгенүләрен ишетүдән сакларга кирәк, куллар тыелганнарга кагылмаска, ә аяклар гөнаһлар кылына торган җирләргә бармаска тиеш. Шулай ук үзеңнең ашказаныңны да сакларга кирәк, ягъни сәхәр белән ифтарга ашала торган ризыкның хәләл булуы шарт. Ураза вакытында ачлыкны һәм хәлсезлекне сизү иманлы кеше өчен игелек кенә.

Рамазан аенда ураза тоту мөселманнарның бурычы, ә өстәмә ураза иманны тагын да ныгыта. Рамазан аеруча бәрәкәтле һәм изге ай. Ураза аенда җитүен мөселманнар тагын да күбрәк изгелекләр эшләү өчен һәм шулар бәрабәренә гөнаһларының ярлыкануын өметләнеп көтеп ала. Аллаһы Тәгалә бу айны башка айлардан аерып куйган: рамазанда тыелганнардан тыелу, үзеңнең гадәтләреңне үзгәртү, Аллаһы Тәгаләгә табыну җиңелрәк башкарыла, бу айда кылынган игелекле эшгамәлләр өчен савап күп тапкырларга арта. Аллаһы Тәгаләнең рамазан аенда иманлы кешегә рәхмәте тагын да арта, шуңа күрә аңлы кеше, уразага ихтирамын белдереп, шушы айда бары игелекләр генә кылырга тырыша.

***"Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән***






# БОЛГАРНЫ ЗИЯРӘТ ШӘРИГАТЬКӘ



**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Хәзерге татарларның Болгарга зиярәт кылуларын дин күзлегеннән карап китик. Елның билгеле бер көнендә шәһре Болгарны зиярәт итүнең, шәригать күзлегеннән караганда, ныклы нигезе бар. Чөнки Бохарида һәм Мөслимдә түбәндәге хәдис китерелә: "Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә килгәндә яһүдиләрнең Гашүрә көнендә ураза тотканнарын белә.

Ул алардан бу көнне ураза тотуларының сәбәбен сорый. Алар: "Бу көнне Аллаһ, Муса галәйһиссәламне коткарып калып, Фиргавенне суга батырып үтергән. Шуңа күрә без Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт йөзеннән бу көнне ураза тотабыз",– дип җавап биргәннәр. Моны ишеткәч, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: "Без Мусага сезгә караганда да якынрак", - дигән. Моннан шундый нәтиҗә чыгарырга була: "Без дә елның билгеле бер көнендә безгә биргән нигъмәтләре өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтебезне белдерергә һәм аны ел саен кабатларга тиеш". Ә аның безгә биргән нигъмәтләреннән ислам динен кабул итүебездән дә зуррак тагын кайсы нигъмәте бар? Шул бәхетле көннән башлап халкыбызның күпме буын вәкиле иманлы булды һәм җәһәннәм утыннан котылуга иреште; ислам динен кабул итү көненнән башлап без туры юлдабыз. Аллаһының бу олуг нигъмәтен, аның безгә күрсәткән өстенлеген тиешенчә аңлау өчен Идел буендагы башка күрше халыкларга күз салу да җитә. Аларга ислам дине ирешмәгән, алар бүгенге көнгә кадәр җаһиллектә. Шулай итеп, ата-бабаларыбызның ислам динен кабул итүен билгеләп үтү – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм күрсәтмәләренә, аның Аллаһы нигъмәтләренә карата булган мөнәсәбәтенә тулысы белән туры килә. Бу – Раббыбызның олуг нигъмәте өчен безнең Аңа булган рәхмәтебезнең бер чагылышы гына.

Болгар шәһәрен халкыбызның зур гыйлемле ата-бабаларыбыз да зиярәт иткән. Мәсәлән, мәшһүр галимебез Шиһабетдин Мәрҗани үзенең "Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) хезмәтендә Мәрҗани мәчетенең өченче имамы Ибраһим хәзрәт Хуҗаш турында сөйләнгән булегендә ул аның Болгарга зиярәт кылуы турындагы язмаларны китерә: "1235 елда (милади белән 1819) андагы тәкъваларның каберләрен зиярәт кылырга мин Болгарга бардым. Аллаһы минем бу гамәлләремне кабул итсен! Әмин! Болгарда зур ике манара бар, аларның берсе җамигъ мәчет янында урнашкан. Бу мәчет баскычында 73 басма. Ә аннан көнчыгышта икенче манара тора, аның баскычында 42 басма. Икенче манарага шәхсән мин үзем дә мендем".

Шул ук китабында Мәрҗани хәзрәтләре үзе турында болай дип яза: "1287 елда (милади белән 1870) мин үз гаиләм белән Болгарны кабат зиярәт кылдым һәм аның манарасы башына менгәч, минем башка шундый уйлар килде: "Бу манарага беркем дә күтәрелмәгән, аннан беркайчан да азан әйтмәгән, анда бервакыт та тәкбир әйтү ишетелмәгән кебек. Болгарда бервакытта да мөселманнар яшәмәгән, алар аның урамнарыннан үтмәгән кебек. Юк, болар барысы да булган, тик вакыт кына элеккене үз вакыйгалары белән җуеп бетергән. Мосафирларда сагыш хисләре уяткан гүзәл Болгарга Аллаһ тынычлык әйләсен".

Ә Шиһабетдин Мәрҗани Болгарга зиярәт кылганда анда монастырь – монахлар общинасы карамагындагы чиркәү эшләп торган! Хәзерге вакытта биредә ислам мохиты тудырылган шартларда берничә нәдан бу изге эшкә аяк чалырга маташа.

Безнең мөселманча милли йолаларыбыз һәм истәлекле көннәребез этник катламнарыбызны үстерүдә, аның тотрыклылыгын, халкыбызның киләчәктә сакланып калуына ышанычны ныгытуда зур роль уйный. Шуңа күрә бездә еллык даталарны, Мәүлидне билгеләп үтү, мөбарәк урыннарны зиярәт кылу киң таралган. Монда аларның нәкъ менә кабатланып баруы әһәмиятле, ул безгә бу вакыйгаларның елъязмага бәйләлеген үтеп чыгарга, ата-бабаларыбызның тәҗрибәсен исәпкә алырга ярдәм итә.

Тарихта шулай килеп чыккан: безнең беренче башкаларны – Болгар белән Биләрне – яулап алучылар җимергән. Алар җирле халыкны тулысынча кырып бетергән, ягъни хәзерге заман сүзләре белән әйткәндә, монда геноцид үткәрелгән. Җирле халыкка монда төпләнеп калу рөхсәт ителмәгән, инкыйлабка кадәр Болгар белән Биләрдә татарлар яшәмәгән. Мөселманлык чорыннан калган тарихи һәйкәлләр: мәчетләр, манаралар, төрбәләр һ.б. юкка чыгарылган. Алар урынына төрле ясалган зийберләр урын алган. Монда монастырь урнашкан булган. Күрүебезчә, халык хәтереннән аның данлы, тәкъва үткәне турындагы хатирәләрне юкка чыгару өчен барысы да эшләнгән. Шуңа да карамастан, халкыбыз үзенең элекке башкалаларын онытмаган. Аларны зиярәт итәр өчен мөселманнар гел килеп йөргән. Күренекле дин галимебез Шиһабетдин Мәрҗани Болгарны ким дигәндә ике тапкыр зиярәт иткән. Ул монда Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сахабәләренең каберен эзләгән. Ә безнең ата-бабалар аларның дингә өндәве нәтиҗәсендә ислам динен кабул иткән.

Мондый зиярәт кылулар колониаль хакимиятнең ачуын чыгарган, ә ул, аңлашылганча, үзенең элекке җинаять эзләрен юкка чыгарырга теләгән. Патша жандармериясе муллалар арасыннан булган түләүле шымчылары аша Болгарны зиярәт кылуның хәрам икәнлеге турында провокацион ялганнар тараткан; имеш, андый зиярәт кылу шикер кату (мәҗүсилеккә ияру) булып исәпләнә икән. Кыганыч ки, бүгенге көндә дә аларның үрнәген нигез итеп алып, Болгарга зиярәт кылуны инкарь итүчеләр бар. Алар Ш.Мәрҗани кебек бөек галимнәрне дә ачыктан-ачык кимсетүдән, аларны имансызлыкта, мөшриклектә гаепләүдән кыенсынмый.

Барысы өчен дә мөкатдәс, кадерле каберлекләре булган шәһәр-авыллар, башка урыннар һәр илдә дә бар. Мәсәлән, Бәдер һәм Өхед сугышында шәһит киткәннәрнең каберлекләре, Дербенттагы (Дагыстанда) сахабәләр каберлеге, Босния-Герцеговинадагы Сребреница, Польшадагы Освенцим һ.б. Бу урыннарны зиярәт кылырга күп кешеләр килә һәм монда берниндә дә ширек кату юк. Болгарга халык бары тик Аллаһыга гыйбадәт кылу өчен генә җыела. Нинди дә булса бер урынны зиярәт кылу берничек тә мөшриклек була алмый, алай дип әйтү – наданлык. Әгәр кем дә булса Кәгъбәгә яки мәчеттә булганда Аллаһыга түгел, ә андагы ярымайга гыйбадәт кылса – бу ширек кату була.

Бер хәдистә әйтелгәнчә, өч мәчеттән тыш калган барлык мәчетләрдә дә гыйбадәт кылуның савабы бер дәрәҗәдә. Мәккә мәчетендә укылган намазның савабы башка мәчетләрдә укылган 100 мең намаз савабына, Мәдинә мәчетендә укылган намазның савабы башка мәчетләрдә укылган мең намаз савабына, Кодус (Иерусалим) мәчетендә укылган намазның савабы башка мәчетләрдә укылган 500 намаз савабына бәрабәр, калган мәчетләрдә укылган намазларның саваплары исә бертигез. Күргәнебезчә, саваплылык дәрәҗәсе өстенрәк башка мәчет эзләүнең мәгънәсе юк. Шунысын да әйтергә кирәк: әгәр максат савабының күбрәк булганын эзләүдән гыйбарәт булмаса, башка мәчетләрдә гыйбадәт кылу берничек тә тыелмаган.

Зиярәт кылу сүзенең мәгънәсе: а) кайда да булса булу, визит; ә) әүлияләр каберен зиярәт кылу, авыру кешене зиярәт кылу.

Зиярәт кылу өч төргә бүленә: а) исән-сау кешеләрне зиярәт итү; ә) ниндидер бер урынны зиярәт итү; б) мәрхүмнәр каберен зиярәт итү.

Хәзер шуларга киңрәк тукталып үтәрбез.

Исән-сау кешеләрне зиярәт итү. Бүгенге көндә исән-сау булган туганнарыбыз, якыннарыбыз, дусларыбызның, галимнәр, тәкъваларның хәлләрен белеп тору – җәмгыять алдындагы бурычыбыз, аларга ихтирам күрсәтүебез, аларны сөю хисләребезне белдерүебез.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм түбәндәгеләрне әйткән:

"Ризыгының киң һәм гомеренең озын булуын теләгән кеше туганнары белән элемтәне өзмәсен" (Бохари, Мөслим).

"Әгәр берәү мөселман кардәшен бер кайгысыннан арындырса – Кыямәт көнендә Аллаһ ул бәндәне бер кайгысыннан арындырыр. Әгәр берәү бер фәкыйрьнең хәлен җиңеләйтсә – Аллаһ аның хәлен бу дөньяда һәм ахирәттә дә җиңеләйтер. Берәү үзенең кардәшенә ярдәм иткәндә Аллаһ аңа Үзенең ярдәмен ирештереп торыр" (Мөслим, Әбү Дауд, Тирмизи, Ибне Маҗәһ).

"Әгәр мөселман кешесе икенче бер мөселман кардәше белән кул биреп күрешсә – аларның гөнаһлары агачтан яфрак коелып төшкән кебек коелып төшәр" (Баззар).

Нинди дә булса бер урынны зиярәт итү. Бу – мөкатдәс һәм мөбарәк урыннарны зиярәт итү. Исламда мөбарәк урыннар дип Мәккәдәге Хәрам мәчетен, Мәдинәдәге Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәчетен, Кодустәге әл-

# КЫЛУ ТУРЫ КИЛӘМЕ?



Әкъса мәчетен һәм мөселманнарның ата-бабалары белән, тарих белән бәйле мөбарәк урыннарны әйтәләр. Әлбәттә, кемдер: “Өч урыннан башка изге урын юк”, - дип моңа каршы чыгарга да мөмкин. Ләкин Коръән буенча андый урыннар күпкә артыграк. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди: “Хактыр ки, Мин ул – синең Раббың. Әйдә, башмакларыңны сал. Син мөкатдәс Тува үзәнендә” (“Та-һа” сүрәсе, 12 нче аять).

Күргәнебезчә, Аллаһы Тәгалә аның изге үзәндә, башка сүзләр белән әйткәндә, изге җирдә булуы сәбәпле, Муса галәйһиссәламгә башмакларын салырга куша. Бу җирләрнең нәкъ менә изге булуы сәбәпле Аллаһы Тәгалә аяк киемнәрен салырга боерганы – ап-ачык, тик бу үзән ул өч урын исемлегендә юк.

Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Әл-Куба мәчетен һәм Өхед тавын зиярәт итүе – әлеге хәдиснең шундый аңланышына тагын бер дәлил. Күргәнебезчә, мөбарәк урыннар өчтән күпкә артыграк.

Шулай итеп, изге урыннарны өч урын белән генә чикләргә кирәкми. Һәр халыкның да үзләренә аеруча кадерле урыннары бар: элек сугыш булган урыннар; истәлекле, данлы урыннар; халыкның рухи, мәдәни мирасы белән бәйле урыннар; халыкның ислам дине белән бәйләнешен күрсәткән урыннар. Әйтик, безгә – татарларга шундый урын булып заманында олуг шөһрәткә ия булган Болгар шәһәре тора. Анда безнең традицияләребез, гореф-гадәтләребез, тарихыбыз сеңгән. Мисалга, хәнәфи мәзһәбенең хокук буенча “Зөбдәтел Маҗәһллә” китабыннан бер өзек китерик: “Шәригать хөкемнәре чыгарылганда җирле мәдәният һәм йолалар игътибарга алынырга тиеш”.

Мәрхүмнәрнең каберләрен зиярәт кылу. Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең мәшһүр хәдисендә: “Мин сезгә каберләрне зиярәт итүне тыйган идем, хәзер исә рөхсәт бирәм, чөнки каберләрне зиярәт итү Кыямәт көнен искә төшерә”, – дип әйткән (Тимизи Мөслим).

Каберлек ул – шундый бер тыныч урын ки, анда кеше үзүзе белән ялгыз калып фикер йөртә, зирәгрәк була башлый, үз яшәеше һәм анда күмелгән кешеләрнең тормышлары турында уйлана, гыйбрәт ала. Каберлекләрне зиярәт итү һәрберебезгә дә киләчәк үлемебезне искә төшерә.

Кеше һәрвакыт ике чынбарлык: яшәү теләге һәм үлемнең котылгысыз булуы арасында яши. Әгәр яшәүнең һәм үлемнең хакыйкый мәгънәсен танымасак, яшәү мәгънәсен беркайчан да аңлый алмаячакбыз. Иманлы кеше өчен үлем – Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән бүләк ул, бер халәттән икенче халәткә күчү. Ә имансызлар һәм гөнаһлы кешеләр өчен үлем җәзага әйләнә. Дөреслектә кешенең ике төп киңәшчесе бар: аларның берсе сөйләүче булса, икенчесе – дәшмәүче. Сөйләп торган киңәшче булып Аллаһның бөек китабы – Коръән тора, ә сөйләшмәүчесе – үлем. Кешеләр менә шушы сөйләшми торган киңәшчедән дәрес, гыйбрәт алсын өчен бабаларыбыз каберлекләрне шәһәрләрнең үзәгендә булдырган.

Үлемнең теле юк, ләкин ул дәшми торса да, аңа тирән мәгънә салынган. Каберлекләр әти-әниләребезнең, әби-бабайларыбызның, туган-тумачаларыбызның, яраткан дусларыбызның исемнәре белән тулыдыр.

Мөхтәрәм җәмәгать, шуны онытмасак иде! Алаһның Рәсүле галәйһиссәлам: “Кабер ул – буш дөнья түгел. Иманлы бәндә өчен ул – җәннәт бакчаларыннан бер бакча. Имансыз кеше өчен җәһәннәм чокырларыннан бер чокыр булачак”, - дигән (Тирмизи). Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе еш кына сахабәләренең каберлекләрен зиярәт иткән һәм алар өчен дога кылган: “Сезгә иминлек, тынычлык насыйп булсын! Әгәр Аллаһ теләсә, без дә сезгә тиздән кушылачакбыз. Мин үзебез һәм сезнең өчен Аллаһы Тәгаләдән бәхет сорыйм” (Мөслим).

Хөрмәтле мөселманнар! Каберләрне зиярәт итү безгә дәрес бирсә, Иншә Аллаһ, мәетләребезгә җиңеллек китерә. Ибне Габбас (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде) риваять итә, бервакыт Рәсүл әкрам галәйһиссәлам ике кабер арасыннан үткәндә болай дип әйткән: “Хәзерге вакытта шушы ике кабердә ятучылар зур булмаган гөнаһлар өчен зур җәза ала. Кабердә ятучыларның берсе гайбәт сөйләп йөргән, ә икенчесе нәҗестән пакьләнмәгән”. Шуннары Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм пальма ботагын сындырып, аны икегә бүлеп, шул каберләр өстенә кадап куйган һәм болай дигән: “Бу ботаклар корыганчыга кадәр шушы кешеләрнең кабер газапларын җиңеләйтеп торыр” (Бохари, Мөслим, Тирмизи).

Танылган мөфәссир (бер нәрсәне аңлатып бирүче) имам Куртуби (Аллаһы Тәгалә аны Үзенең рәхмәтенә ирештерсә иде) бу хәдисне болай дип шәрехли: “Бу ботаклар корыганчыга кадәр” дигән сүзләр шуны аңлата: әгәр кабергә үсемлекләр утыртылса яки Коръән укылса – мәетләр җиңеллек сизә. Әгәр бер үсемлек мәетнең хәлен җиңеләйтсә – Коръән уку аңа тагын да күбрәк җиңеллек бирәчәк”.

Әгәр мәетләребезгә Коръән укылса (бигрәк тә Йәсин” сүрәсе), аларга Аллаһының рәхмәте ирешәчәк. Мәетләргә “Йәсин” сүрәсен уку турындагы хәдисшәрифтә болай диелгән: “Йәсин” сүрәсе Коръәннең калебе булып тора. Дөреслектә Аллаһының ризалыгын һәм киләсе дөньяда Аллаһының рәхмәтен алу нияте белән “Йәсин” сүрәсен укыган кешенең гөнаһлары гафу ителер, шулай булгач, мәетләрегезгә “Йәсин” сүрәсен укыгыз” (Әхмәд бине Хәнбәл, Муснад).

Аллаһының Рәсүле галәйһиссәлам әйткән: “Әгәр сезнең берәрегезгә үлем ирешсә – аны тиз арада күмәргә тырышыгыз. Мәетне күмгәннән соң аның баш очында “Фатиха” сүрәсен, ә инде аяк очына басып “Бәкара” сүрәсенең соңгы аятьләрен (Әмәнәрәсүл) укыгыз” (Имам Табарани, Дәйләми, Хәйсәми).

Имам Нәвави (Аллаһы Тәгалә аны Үзенең рәхмәтенә ирештерсә иде) “Риязус-салихин” (“Изгеләр бакчасы”) дип исемләнгән китабында имам Шәфигый (Аллаһы Тәгалә аны Үзенең рәхмәтенә ирештерсә иде) сүзләрен китерә: “Кабер янында Коръәни-Кәримнән аятьләр һәм сүрәләр уку яхшы гамәл булып санала, әмма Коръәнне тулысынча уку – тагы да яхшырак”.

Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә Коръәндә мәетләребез өчен дога кылырга өйрәтә: “...Раббыбыз, безне һәм бездән элек килеп киткән иманлы кардәшләребезне ярлыка; күңелләребездә иман китергәннәргә карата һичбер хөсетлек калдырма. Раббыбыз, шик юк ки, Син – чиксез шәфкатьле, чиксез мәрхәмәтле” (Хәшер (Сөреп чыгару)” сүрәсе, 10 нчы аять).

Мөхтәрәм мөселманнар! Монда начар гадәтләргә, ягъни бидгатьләргә игътибар итәргә һәм шулардан ерак булырга кирәк. Ислам галимнәре үзләренең китапларында каберлекләрне зиярәт итү кагыйдәләрен, әдәпләрен аңлаткан булса да, хәзерге көндә кайберәүләр дини наданлыклары аркасында кабер өстендә шәм кабыза, кәгазьләргә, чүпрәкләргә үзләренең теләкләрен язып, аларны чардуганга яисә кабер өстендәге агач ботакларына бәйләп куя. Башкалар исә, икенче чиккә тайпыла, каберлекләрне зиярәт итүчеләрне ширектә гаепли. Без гамәлләр кылганда бер чиктән икенче чиккә тйпылмаска, урталыкны тотарга тиешбез.

Ибне Габбас (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде) риваять кыла: “Сәгъд бине Губәдә (Аллаһы Тәгалә аннан разый булса иде) дигән сахабәнең әнисе үлгәч, ул Пәйгамбәребез галәйһиссәлам янына килеп: “Йә, Рәсүлуллаһ, минем әнием вафат булды. Ул үлгән вакытта аның янында була алмадым. Әгәр әнием өчен үз җиләк-җимеш бакчамны сәдака итеп бирсәм, бу гамәлем аңа файда китерер микән?” – дип сораган. Аллаһының Рәсүле галәйһиссәлам: “Әйе”, - дигән.

Безне хак юлга өндәүче Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән: “Кеше вафат булганнан соң ул барлык гамәлләреннән өзелә, ләкин аның өчен өч төрле гамәле файда китерәчәк: сәдакател-җария, ягъни кеше үлгәннән соң да файда китерә торган сәдака; башкаларга биреп калдырылган белем; балаларының догалары” (Мөслим).

Мөхтәрәм җәмәгать! Хәдисләрдән күренә ки, мәетләребез өчен Коръән уку, сәдакалар бирү һәм башка изге гамәлләр кылу – аларга җиңеллек һәм савап китерә. Һәркайсыбызга тарихыбызны, изге урыннарыбызны, шәхесләребезне белергә һәм хөрмәт итәргә насыйп булсын. Аллаһы Тәгалә барчабызны Үзенең чиксез рәхмәтеннән аермасын.

**Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге**
**“ШУРА”, №8**

# ҮЛГӘННӘРНЕҢ КАБЕРЕН БЕЛИК,



**Ислам динен кабул итүнең мең еллыгы исемендәге мәдрәсәдә күркәм бер традиция яши: мөгаллимнәр, шәкертләр, бу уку йортын тәмамлап, имамлык итүчеләр ел саен 2 май көнне Яңа бистәдәге Иске татар зиратына, остазлары каберен зиярәт кылырга баралар. Унынчы тапкыр үткәрелә торган бу чара турында Казанда, Татарстанда гына түгел, Россиянең татарлар яшәгән башка төбәкләрендә дә беләләр. Шунлыктан чараның быелгысына төрле төбәкләрдән дин әһелләре, милләт зыялылары килде; Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Ханты-Манси автоном округы мөфтие, төбәкнең татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Таһир хәзрәт Саматов, халык шагыйре, Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Бөтендөнья татар конгрессының Казан оешмасы рәисе Фәрит Мифтахов, күренекле имамнар, татар зыялылары, журналистлар, мөгаллимнәр, шәкертләр катнашты.**



Искә алу мәрасимен мәдрәсә идарәсе Бөтендөнья татар конгрессының Казан бүлекчәсе белән берлектә уздыра. Оештыручылар үзләре: "Бу без башлаган, без керткән яңалык түгел, - диләр. - Безнең татар авылларында мондый матур гадәт күптән бар. Кайткан саен без зират буен, ата-бабалар, әни-әбиләр каберлекләрен әйләнеп кайтабыз. Бу безнең халыкның канына сеңгән гореф-гадәте".

Быелгы хәтер чарасы Бөек Җиңүнең 70 еллыгын каршылаган көннәргә туры килүе белән дә истәлекле. Зиярәт кылучылар сугыш кырларында ятып калган, сугыштан соң яралардан мәрхүм булган кардәшләребезне искә алдылар.

Җиңү елында Ураза вә Корбан гаетләре сугыш беткәч уздырылган. Халык искиткеч күтәренке рухта булып, дини бәйрәмнәребезне зурлап үткәргәннәр. Сугыштан кайткан мөселман кардәшләр күмәкләшеп, Яңа бистәдәге Иске татар зиратында җирләнгән мәрхүмнәр каберләрен зиярәт кылганнар, догалар укып, исән-имин кайтканнарына Аллаһы Тәгаләгә шөкер иткәннәр. Аларның инде күбесе мәрхүм, кайсылары шушы зиратта ук җирләнгән. Мәдрәсә фондында шул вакытларда төшерелгән кинотасма да саклана.

Бу юлы искә алырга килүчеләр – чараны оештыручылар һәм кунаклар – дин әһелләре һәм зыялылар яд итүне Габделхак хәзрәт Саматов кабереннән башладылар. Мәрҗани мәчете имамы, Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые булып торганда ихласлыгы, риясызлыгы, дин юлындагы фидакарьлеге белән танылды. Икенче булып тукталганы - Габделхак хәзрәт Каюмов исә совет хакимияте елларында, барлык теләгәннәргә дин нигезләрен, гарәп язуын өйрәткән остаз. Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин, Гарифулла хәзрәт Гайнуллин, Зәкәрия хәзрәт Минвәлиев, Әхмәтһади Максуди, Галимҗан һәм Салихҗан Барудилар, Габделхәбир хәзрәт Яруллин, Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләрнең дә баш очларында Коръән аятьләре укып, дога кылып мәшһүр бабаларыбызның рухлары алдында баш иделәр. Зиярәт кылу Бөек Ватан сугышында шәһит булган кардәшләр хөрмәтенә куелган истәлек билгесе янында дәвам итте. Күренекле татар зыялыларын да искә алдылар - Габдулла Тукай, Туфан ага Миңнуллин, Шамил ага Зиннуров, Мирхәсыйм ага Госманов каберләре янында тукталып, аларны җылы итеп искә төшерделәр.

Аллаһы Тәгалә аларның барчасына күрсәткән фидакарьлекләре, күргән авырлыклары вә газаплары өчен җәннәт нигъмәтләрен бирсә иде.









# ИСӘННӘРНЕҢ КАДЕРЕН БЕЛИК

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте сугыш һәм тыл ветераннарын Җиңү бәйрәменең 70 еллыгы уңаеннан оештырылган тантаналы мәҗлескә җыйды. Авыр сугыш елларында үзләренең батырлыклары, фидакарь хезмәтләре белән җиңүгә зур өлеш керткән өлкәннәрне бәйрәм белән котларга Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин килде.**



"Туган Авылым" ресторан-күңел ачу комплексына 40 ка якын сугыш ветераны һәм тыл хезмәткәре чакырылган иде. Илгә дин ирегә кайтканнан соң, ветераннарның күбесе дини эшчәнлек алып барган, республика районнарында имамлык иткән. Алар әле дә мәхәллә эшләрендә актив катнаша, рухи кыйммәтләрне халкыбызга җиткерү өчен зур тырышлык куя.

" Мөхтәрәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл батырлары! Диния нәзарәте һәм үз исемемнән сезне Җиңү бәйрәме белән котлыйм! Аллаһы Тәгалә сезгә исәнлек-саулык, озын гомер һәм күңел тынычлыгы бирсен. Картлык көннәрегездә кадер-хөрмәттә, балалар, оныклар бәхетен, шатлыгын күреп яшәргә насыйп булсын.

Сугыш илебезгә бик күп михнәтләр, газаплар алып килгән. Ул михнәтләр өлкәннәрне дә, балаларны да урап узмаган. Бабайларыбыз, әбиләребез сөйләгәннәрдән ишетеп беләбез, алар сугыш кайгысын Аллаһы Тәгаләдән ялварып ярдәм сорап күтәргәннәр; динебез өйрәткәнчә сабыр итәргә тырышканнар, бер-берләренә карата миһербанлы булганнар; Җиңү көнен Аллаһка рәхмәтләр әйтеп каршы алганнар. Сугыш һәм тыл ветераннары күтәргән авырлыкларны алга таба күрергә язмасын иде. Динебез дә үзара килешеп, аңлашып яшәргә чакыра.

Аллаһка шөкер, хәзер ил-көннәр тыныч, балаларның өсте бөтен, тамагы тук. Менә шушы мул, тыныч тормыш хакына сугыш кырларында гомерләре өзелгән сугышчыларның рухларына дога кылырга онытмасак иде. Шулай ук, өлкән яшькә җиткән, тормышның ачы михнәтен күргән һәм бернинди сынауларга да бирешмәгән ветераннарны хөрмәтләп, зурлап торсак, бу үзе бер изгелек булыр.

Аллаһы Тәгалә илебезгә бәхет һәм бәрәкәт насыйп итсен, рәхим-шәфкатеннән ташламасын", – диде мөфти үзенең чыгышында.





Чарада шулай ук Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә ярдәм фонды директоры урынбасары, фондның Координацион үзәге җитәкчесе, Төньяк Кавказда Кеше хокукларын яклаучы милли иҗтимагый комиссия җитәкчесе урынбасары Эдуард Хачукаев, Татарстан мөфтие урынбасарлары һәм район мөхтәсибләре катнашты. Эдуард Хачукаев барлык ветераннарны Җиңү бәйрәме белән котлады һәм һәркайсына саулык-сәламәтлек, озын гомер, бәхет теләде.

Әлеге күркәм мәҗлесне алып барган Аксакаллар шурасы рәисе, Нурлат районы мөхтәсибе Айрат хәзрәт Әюпов һәр ветеранга сүз бирде. Алар сугыш елларын хәтерләрендә яңарттылар, тормыш хәлләре хакында сөйләделәр.

Очрашу барышында сугышта мәрхүм булганнар рухына дога кылынды һәм мөфтият исеменнән күчтәнәчләр өләшенде.





# ВАТАННЫ ЯРАТУ - ИМАННАН

**Хөрмәтле дин кардәшләрем! Җиңүнең 70 еллыгы илебез өчен, һичшиксез, мөһим вакыйга. Россиядә Бөек Ватан сугышы кагылмаган гаилә юктыр, һәркайсыбызның нәсел-нәсәбендә гасырларга торырлык бу вакыйга нинди дә булса эз калдырган. Шуңа күрә дә нәкъ менә 9 Май - Җиңү бәйрәме, ата-бабаларыбызның иңгә-иң торып уртак дошманга каршы берләшкәне кебек, бөтен илебезне берләштерә.**

Без, мөселманнар, илебезгә Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән әлеге олуг сынауның мәгънәсен төшенергә тиеш. Сугыш еллары динебез өчен шактый катлаулы чор булса да, мөселманнар, башка конфессия вәкилләре белән берлектә уртак Ватаныбызны саклаган. Шул чордагы мөфти Габдрахман Расүлев дин кардәшләрен әлеге изге сугышта катнашырга чакырып мөрәҗәгать белән чыга. Ул мөрәҗәгать Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең: "Ватанны ярату - иманнан", - дигән хәдисе белән башлана.

Дини оешмалар сүздә генә түгел, гамәлдә дә булдыра алганча җиңүгә үз өлешләрен керткән. Әйтик, барлык мәчетләрдә дә танк колоннасы төзү өчен акча җыю оештырганнар. Мөселманнарның әлеге ярдәме өчен Илбашы И.Сталин мөфти Г.Расүлевкә Рәхмәт хаты да җибәргән. Шунысын да ассызыклау кирәк, сугыш чорына бәя биргәндә без - мөселманнар өчен ул чактагы сәяси режимның нинди булуы артык мөһим түгел. Сүз дә юк, без атеистик режим белән килешә алмыйбыз, әмма Ватан - гамәлдәге сәяси вазгыятьтән югары торучы төшенчә. Режимнар килә, үзгәрә, ә туган җир кала. Шуның өчен мөселманнар Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен Ватаннарын саклаганда гомерләрен кызганмаган. Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәте буенча, Ватанны яклау ул - һәр мөселманның бурычы. Шуңа да Бөек Ватан сугышын без, сәяси режим һәм Ватан төшенчәләре арасында гаять зур аерма булуын аңлаган хәлдә, изге сугыш дип атый алабыз.

Тагын бер мөһим сабак: Бөек Ватан сугышы кебек тетрәндергеч вакыйга диннең какшамаслыгын, "яу кырында атеистлар булмый" дигән гыйбарәнең хаклыгын раслады. Үзләрен коммунист, атеист дип атаучыларның да Бөек Ватан сугышында үлем белән йөзгә-йөз очрашкач, фитрый иманнары уянган. Гәрчә, рәсми сөйләмнәрдә йөрәктәге яралгы хәлендәге иманын басарга тырышкан булса да, соңгы сулышы якынлашканда һәркемдә уяна ул. Бу - кеше тормышында диннең фундаментальлеген күрсәтә торган хакыйкать тә. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә әйтелгәнчә, кеше фитрый иман белән туа. Иман ул - кешенең табигый халәте. Шушы табигый халәтне рәсми идеологияләр, доктриналар күпме генә томаларга тырышса да, иртәме-соңмы ул барыбер өскә калкып чыга. Әлеге җәһәттән караганда, сугыш - кешенең чын табигатен ачып бирә торган "корал", иманның никадәр фундаменталь булуын күрсәтүче вакыйга.

Яу кырында элекке коммунистларның да иманнары уянган, дидек. Мисал өчен Җәлилчеләр язмышын гына алыйк. Алар барысы да үләр алдыннан кулларын Коръәнгә куеп, дөнья белән хушлашкан. Ә бит алар коммунист булган һәм атеистик идеологияне кертү өчен тырышлык куйган кешеләр. Әмма Аллаһы каршына барыр сәгать суккач, ул идеологияләр онытылган... Дәүләт тә моны аңлаган һәм православие диненә дә, ислам диненә дә карашын үзгәрткән, тезгенне йомшарткан.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә хәбәр ителгәнчә, әгәр берәр кеше ихлас күңел белән намаз укудан туктый икән - бу кавемгә Аллаһы Тәгалә тормышларын астын-өскә китерерлек җәза бирә. Гомумән, сугышны эпохаль, хәрби, сәяси вакыйга гына итеп түгел, төрле яклап карарга кирәк. Шул исәптән, Аллаһы Тәгаләнең безгә бу тормышны яхшырак аңлар өчен биргән бер дәресе итеп тә.

Яшьләр Бөек Ватан сугышы биргән сабакны оныта. Без хәзер неофашизмның яңа төсмер алып баш калкытуын күрәбез. Гитлер Советлар Союзын җиңгән булса, хәзер Европада яшәр идек, тормышыбыз яхшырак булыр иде, дигән фикерләр дә ишетергә туры килә. Мондый фикерләр белән без килешә алмыйбыз. Ата-бабаларыбыз, чын мәгънәсендә, иребегезне саклап калган, коллыкка төшермәгән. Без аларның батырлыгын онытырга тиеш түгел. Үсеп килүче яшь буынга сөйләргә тиеш. Үзебез дә аларның батырлыгында, ватанпәрвәрлегендә тәрбияләндек бит. Хәзер аны яшьләргә тапшыру - безнең бурыч.

**Рөстәм хәзрәт БАТРОВ, Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары**

# Чаллының Ак мәчетендә ветераннарны хөрмәтләү мәҗлесе булды

Чаллының "Ак мәчете"ндә Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан ветераннарны, тыл хезмәтчәннәрен, сугыш чоры балаларын хөрмәтләү мәҗлесе булды. Анда башка мәчетләрдән дә ветераннар катнашты. Мәҗлес барышында мәчетнең имам-хатыйбы, төбәк казые Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев, шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин тантана сәбәпчеләре адресына бик күп җылы сүзләр әйттеләр, аларны Бөек Җиңүнең 70 еллыгы белән кайнар котладылар. Сугыш ветераны Мостафа ага Хәйбуллов сугыш истәлекләре белән уртаклашты.



Сугыш ветераны Габделхәт ага Борһанов үз чыгышында мәчет имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәтнең ветераннар турында һәрдаим кайгыртуын билгеләде, динебез нигезләрен тырышып үзләштергән "Ак мәчет" мәдрәсәсе шәкертләренә, мәҗлестә катнашкан башка яшь кешеләргә шулай дин юлына бастырганнары өчен ата-аналарына үзенең рәхмәт сүзен җиткерүне сорады. Сугыш чоры балалары исеменнән мәчетнең якшәмбе мәктәбе мөгаллиме Флюр Галиуллин, Тау мәчете имам-хатыйбы Габделәзәл хәзрәт Нәҗметдинов чыгыш ясадылар. Яшьләргә күп үгетнәсыйхәтләр бирелде. Ветераннарга мәҗлес ахырында күчтәнәчләр таратылды.

# Тынычлыкта яшәргә язсын!

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Казанның Тынычлык мәчетендә сугыш һәм тыл ветераннарын зурлау чарасында катнашты.

Җиңү бәйрәме уңаеннан уздырылган чарага мәчет мәхәлләсендә яшәүче өлкән буен вәкилләре җыелды. Корьән укудан башланган очрашуда мөфти аларны бәйрәм белән котлады. "Раббыбыз сезгә, туганнарыгызга, якыннарыгызга бәхет, сәламәтлек, ныклык бирсен! Сез кичергән сугыш газаплары башка беркайчан да кабатланмасын һәм күгебез һәрчак аяз булса иде! Аллаһы Тәгалә бәрәкәтен бирсен һәм балалардан, газаплардан сакласын. Туган җирләребездә тынычлык саклап, бер-беребезне хөрмәт итеп яшәргә язсын", - дип теләде мөфти хәзрәтләре.

Очрашу ахырында "Тынычлык" мәчете мәхәлләсе исеменнән өлкәннәргә бүләкләр тапшырылды.

# Казанның Гаилә мәчетендә сугыш һәм тыл ветераннары очрашты



Гаилә мәчетендә Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре белән чәй табыны артында җылы очрашу узды. Аны мәчет коллективы Диния нәзарәтенең "Хузур" нәшрият йорты һәм "Зәкят" хәйрия фонды белән бергәләп оештырды. Корьән укып, дога кылганнан соң мәхәллә балаларының чыгышы тәкъдим ителде. "Сугыш афәтләре рухыгызны сындыра алмаган, ачлы-туклы көенчә дә Ватан өчен, безнең якты киләчәк өчен көрәшкә күтәрелгәнсез - балаларга гыйбрәт итеп әнә шул хакта сөйләгез. Ватанны хөрмәт итәргә, туган җирнең, маңгай тире белән игелгән ризыкның кадерен белергә өйрәнер өчен сезнең үрнәк безгә бик кирәк. Барысына да рәхмәт сезгә, хөрмәтле ветераннар, Аллаһы Раббыбыз һәркайсыгызга сәламәтлек, иминлек, бәрәкәтле гомерләр насыйп итсен", - диде Татарстан мөфтие урынбасары, Гаилә мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин үзенең вәгазендә. Җавап итеп, ветераннар да хатирәләре белән уртаклаштылар. Бөек Ватан сугышы ветераны Камил Рамазанов исә Җиңүнең 70 еллыгына багышлап язган шигырен да укып күрсәтте. Кунакларның да, мәҗлесне оештыручыларның да уртак фикере яңгырады ул шигъри юлларда:

*"Дөньяларга тынычлык бир, Раббым,*
*Ирек кылма явыз көчләргә!"*

# Түбән Камада Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан спорт ярышлары үтте

Түбән Каманың "Батыр" спорткомплексында "Эй, егетләр!" дип исемләнгән бәйге узды. Чарада Алабуга, Сарман, Кама Аланы, Актаныш, Чирмешән, Яңа Чишмә, Әлмәт, Әгерҗе районнары мөселманнары катнашты. Шулай ук Башкортстан Республикасыннан да килгән спортчылар булды. Алар волейбол, гер күтәрү, кул көрәше, иректе көрәш, дартс һәм канат тарту буенча көч сынашты.

Гер күтәрү буенча: Илсур Нәбиуллин (Яңа Чишмә) - 1 нче, Рамил Шәрифуллин (Яңа Чишмә) - 2 нче, Айрат Әсхәмов (Алабуга) 3 нче урынны алды. Кул көрәше буенча 1 урын - Илсур Нәбиуллинда (Яңа Чишмә); Эльмир Фәтхетдинов (Әгерҗе) белән Фәнил Мостафин (Чирмешән) 2-3 урыннарны бүлеште. Дартс ярышында Азат Закиров, Әхәт Хәбиев һәм Илназ Сәлаховка тиңнәр булмады. Волейбол ярышында исә беренчелекне Яңа Чишмә командасы алды, 2 нче урында - Актаныш спортчылары, 3 нчедә - Түбән Кама вәкилләре. Ирекле көрәш 9 үлчәү категориясендә үтте. Әлеге ярышта Түбән Кама, Уфа, Кама Аланы, Алабуга спортчыларына тиңнәр булмады.

Җиңүчеләрне район мөхтәсибе Йосыф хәзрәт Дәүләтшин тәбрикләде һәм мөхтәсибәт исеменнән рәхмәтен белдерде. Барлык җиңүчеләргә дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды. Бу бәйге мөселман яшьләре арасында ел саен Бөек Җиңү уңаеннан оештырыла. Киләсе ярышлар Кама Аланында булыр дип көтелә.

# “БЕЛЕГЕЗ, БАТЫРЛАР ВАТАНГА ХЕЗМӘТ ИТТЕ!”

*Салихов Харис Салих улы 1927 елда Татарстанның Балтач районы Чутай авылында туа. Авыл мәктәбендә укыган вакытында әтисе аны ислам гыйлемнәренә һәм гарәпчә укырга өйрәтә. Чутай җидееллык мәктәбен тәмамлаганнан соң Арча педучилищесына укырга керә. 1944 елда фронтка китә. Яу кырында күрсәткән батырлыклары өчен Ватан сугышының II дәрәҗәле ордены һәм 20 дән артык медаль белән бүләкләнә. Сугыштан соң Мәскәүдә һәм Казанда хокук саклау органнарында эшли. Гадел һәм профессиональ юрист буларак танына. 1972 елда Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән. Публицист А.Станислав сүзләре белән әйтсәк: «Малай һәм сугышчы; коммунист һәм мөселман; милиционер һәм имам, мөфти урынбасары; крестьян малае һәм профессор атасы; кыйлган һәм танылган; гади шәхес һәм теолог, академик, Россия гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы – болар барысы да бер кеше, аксакал Харис Салихҗан язмышына сыйган»... Харис абый бүген дә актив, аның һәр көне зур түрәләрнеке сыман минуты-сәгате белән планлаштырып куелган. Шул планга «төзәтмә» кертеп, мөбарәк җомга көннәренең берсендә мөхтәрәм шәхесебез Харис хәзрәт Салихҗан белән очрашып, сугыш хатирәләрен тагын бер кат хәтердә яңартып алдык. Максатыбыз Бөек Ватан сугышы елларында дингә нинди мөнәсәбәт булуын имамыбызның үз авызыннан сөйләтү иде...*



**СУГЫШ** вакытында динне тыю булмады. 43-45 елларда бер генә частьтә дә бер генә кеше дә тыймады аны. Хәрби җитәкчеләр арасында Аллаһка мөрәҗәгать иткән, дога кылган кешене түбәнсетү дә, шул ук вакытта “дога кылыгыз әле” дип әйтүче дә булмады. Унҗиде яшем тулганда – 1944 елны мине армия сафларына чакырып алдылар. Бер үземне генә түгел. Авылыбызның бөтен яше-карты безне сугышка озатып калды. Ул чактагы елашулар кичә генә булган шикелле. Әби миңа: «Бишмәтеңә «Ясин» сүрәсен тектем, югалта күрмә», – дигән иде. Дөрестән дә, мин аны югалтмадым, ул әле хәзер дә саклана...

Яу кырында ярты ел гына булган кешемен, әмма аның һәр көне – йөрәктә.

1945 елның март аенда Венгриядә каты сугышлар булды. Без НКВД гаскәре – гел алгы сафта. Үлем белән күзгә-күз очрашабыз. Балатон күле янында безне 3 сәгать тоташ бомбага тоттылар. Аны сүз белән генә әйтә, аңлата торган түгел. Фашист шулкадәр явыз, Гитлерның сайлап алынган гаскәре белән сугышабыз.

... Сазлыктагы түмкәкләр арасына кереп яшеренергә мәҗбүр булдык. Башны гына чыгарып ятабыз. Суык. Фашистлар безне бертуктаусыз бомбага тота. Иманы көчәеп китте күрәмсең, Сәгъдулла исемле иптәш малай: “Яшьтәш, үтерәләр бит, әйдә, укы әле”, – диде. “Әлхәм” сүрәсен укыйм. Сәгъдулла тагын “укы!” ди, мин тагы укыйм... Укы да укы, диләр. Аллаһының рәхмәте, безнең отделениедән берәү дә үлмәде, Кәримов Нургаян исемле солдатның гына аягы яраланды. Ә үлүчеләр бихисап күп иде. Әлеге вакыйгадан соң татар малайлары сизеп алды укысаң исән каласың икәнлеген. Һәр сугышка керер алдыннан Сәгъдулла да, Нургали дә, башкалар да “укы!” диләр иде.

Вена операциясе алдыннан Сәгъдулла әйтә: “Әйдә, яшьтәш, намаз укыйк”, – ди. Бөтен бер фронт яуга әзерләнгән вакыт бу. Без, сугышка әзерләнүчеләр – 17 яшьлек, 40-50 килолы малайлар инде. Күбебез русча да рәтләп белми. Дөресен әйтергә кирәк, безне килүгә үк өлкәнрәкләргә беркеттеләр. Русларга. Алар барысы да йә коммунист, йә комсомол. Вена операциясендәге бурычыбыз алдагыларына караганда катлаулырак иде.

Без бер батальонда 30 лап татар малае идек. Әйткәнемчә, малайлар: “Әйдәгез, операция алдыннан намаз укыйк”, – диделәр. Һәр солдатта плащ-палатка бар, намазлык урынына шуны җәябез. Мин – имам. Малайлар мин ниш-лим, шуны эшли. “Намаз укысаң, үлмисеңме?” – диләр. Мин әйтәм: “Үлмисең. Ихлас ят та, Аллаһтан сора”. Сәҗдәгә яткач малайлар “йә Аллаһ, йә Аллаһ...” дип елыйлар. Бик җитди хәрби операциягә әзерләнәбез бит. Бертуктаусыз комсомол җыелышлары бара. Бертуктаусыз үгетләү бара. Бертуктаусыз аңлату бара... Сугышырга өйрәтәләр. Ә без намаз укыйбыз шушы өйрәтүләрдән бушаган арада.

Вена операциясендә безнең бурыч – операция башланганчы 5-6 сәгать алдан Дунайны кичеп чыгып, плацдарм алу иде. Иллеләп көймә. Һәр көймәдә 15 тән артык солдат. Дунай елгасын кичәргә тотынган идек кенә, немецлар безне бомбага тота башлады. Без тиз-тиз ишәбез, бомба йә алга төшә, йә янга, йә артка. Малайлар миңа “укы, укы” диләр. Мин укыйм да укыйм. Ярга чыгып җитәргә йөз метр чамасы калгандыр, көймәбез башына мина төште дә әйләнеп капландык. Без су астыннан йөзеп чыгып аның сыртына ябыштык. 18 малай идек. Икебез юк. Мин – отделение командиры. “Иптәш кызылармеецлар, паникага бирелмәгез, хәзер безнең бурыч – гомеребезне саклау!” – дип әмер бирдем. Кычкырып-кычкырып: “Паникага бирелмәскә!” – дигән сүзләрне кабатлыйм. Көймәгә ябышкан хәлебездә Дунай буйлап агып барабыз. Менә күп тә үтмәде атыш арасына килеп кердек. Бер яктан фашистлар ата совет солдатлары дип, ә икенче яктан, немецлар дип уйлап, безнекеләр. Менә шунда чын паника башланды. Ун минутлап барды бу хәл. Бер генә солдатыбыз югалды. Ничек төшеп киткәнен күрми дә калдык. Караңгы төн. Салкын дулкын дәһшәт белән безгә китереп бирә. Тагын хәрби зонадан чыктык. Атыш бетте. Агабыз да агабыз. Сәгать ярым – ике сәгать тирәсе аккач, хәлебез бетте. Бармаклар, куллар кабарып чыкты. Туңа башладык. Көймә сыртына тотынган килеш агабыз бит. Тотынырлык урыны да юк рәтләп. Күпмедер вакыттан соң тагын бер малаебыз юкка чыккач, Сәгъдуллага әйтәм: “Әйдә, каешларны башка бәйлик”, – дим. Ике кешене тоташтырырлык итеп, каршы як белән башны башка якынайтып каеш белән муеннан бер-беребезгә бәйләндек. Дулкын китереп бәргәндә төшеп китмәскә, ныграк тотынып торыр-га шәп мөмкинлек булды ул. Без барыбер үләбез дип уйлыйбыз инде. Бик каты туңдык та... Күңеле төшкәндәр, Сәгъдулла: “Әйдә, “Ясин”не укы”, – диде. “Ясин”не начар беләм, дим. Белгән кадәр укы, ди. “Ясин” сүрәсен укый башладым...

Шулвакыт бер пароход үтеп китте. Фронтка таба. Без дулкын арасында калдык. Сигнал бирер идек, кычкырырга – тавыш, атарга корал юк. Шуннан Нургали әйтә: “Малайлар, үләбез, Аллаһ безгә шулай язган”, – ди. Укы, ди миңа. Миннән башка укый белүче юк... Тагын бер пароход... бу юлы яныбыздан гына узып китте. Безне күрерләр дип шулкадәр өметләндек инде, тик... күрмәделәр. Бик тә үкенечле булды. Пароходның бусы да узып киткәннән соң, көчле паника башланды. Инде күпме акканыбызны да белмибез. Тагын бер малаебыз юкка чыкты. Бөтенесе дә Дунай төбенә китеп бардылар. Алай да уннан артык калдык әле. Татарлардан берне генә югалттык. Каеш тота безне, муен тота. Баш башка тигән. Минеке Сәгъдулла белән. Болай эшләү шактый җиңеллек бирде безгә. Менә тагын бер пароход килә. 300-400 метр ераклыкта булгандыр бездән, туктады бу. Туктады да прожектор белән Дунай өстен яктырта башлады. Көтәбез инде безгә кайчан төшәр икән дип. Йә Аллаһ, йә Аллаһ, безгә төшсә иде, дибез. Миңа тагын “укы да укы” диләр. “Әлхәм”не укый башладым. Сиңа гына гыйбадәт кылабыз, синнән генә ярдәм сорыйбыз, дибез бит бу сүрәдә. Бөтен дөньяны яктырта. Шактый вакыт яктыртты, әмма безгә төшми. Тагын паника башланды...

Һәм менә, Аллаһның рәхмәте, берзаман безгә дә төште. Яктылык эчендә калдык. Яктырттылар да, яктылыкны алмыйлар, гел безнең өстә тора. Безне күргәннәрен аңлап алдык. Шатланыргамы, шатланмаскамы – белгән юк. Болар кемнәр икән, фашистлармы, венгрлармы, әллә безнекеләрме, дибез.

Күпмедер вакыттан соң яныбызга ике көймә йөзеп килде. Без “товарищи, товарищи” дибез. Болар “другари, другари” диләр. Югославлар икән... Соңрак без Дунайда йөз чакрым тирәсе акканыбызны белдек.

...Австралиянең башкаласы Венаны яулап алган көн – 13 апрель. 15 апрельдә совет гаскәрләре, ә алар белән бергә НКВД батальоннары да сугыша-сугыша Санкт-Пельтен – Тулын-Корнейбург линиясенә барып җитеп, анда Америка гаскәре белән очрашты. Шул рәвешле Вена операциясе тәмамланды.

***

Мин гомерем буе кешелеклелек тәгълиматы тарату тарафдарымын. Бөек Ватан сугышы тәмамлануның 70 еллыгы якынлашкан көннәрдә дә илебезгә килгән шушы олы афәт хакында бәхәсле сүзләр, ялган-боһтаннар язучылар, сөйләүчеләр бар. Гомерләрен бәндәләр иминлегенә багышлаучыларның каһарманлыгына күләгә төшерергә тырышучылар бар. Мин аларны кискен тәнкыйтьлим: “Белегез, батырлар Ватанга хезмәт итте!”

**Фронтовик хатирәләрен**
**Нурия ӘЛМИЕВА язып алды**

***

**ТР МДНнең “ХУЗУР” нәшрият йорты “Мөселманнар Бөек Ватан сугышында. Мусульмане в Великой Отечественной войне” дигән китап нәшер итте. Җыентыкны журналист Нурия Әлмиева төзегән. Югарыда тәкъдим ителгән “Фронтовик хатирәләре” дигән язма да әлеге китаптан алынды.**



# КАЮМ БАБАЙ ФӘЛСӘФӘСЕ

**Быел бөек татар мәгърифәтчесе, галим-энциклопедиста Габделкаюм Насыйриның тууына 190 ел тулды. Шул уңайдан Татарстанда төрле чаралар - конференцияләр, түгәрәк өстәлләр узды; галимнең замандашлары тарафыннан тулысынча яклау тапмаган һәм бәяләнмәгән олы мирасы кабат барланды...**



Каюм Насыйри 1825 елның искечә 14 февралендә хәзерге Яшел Үзән районының Олы Шырдан авылында туа. Аның балачагы мәдәниятле гаиләдә, туган авылында уза. Башлангыч белемне ул атасыннан ала, аннан соң Казанда мәдрәсә тәмамлый, гарәп-фарсы телләрен өйрәнү өстенә, үзлегеннән татар телен дә яхшылап үзләштерә, русча да укый; ирекле тыңлаучы булып йөргәннән соң Казан университетында белем ала. Духовное училищеда, семинариядә татар теле укытучысы булып эшли, татар балаларына рус теле укыта. 1879 елдан башлап калган гомерен Насыйри, рәсми рәвештә бер җирдә дә хезмәт итмичә, бары тик язучылык эшенә һәм фән хезмәтенә генә багышлый.

Әлеге сәхифәдә укучылар игътибарына аның урта гасыр әдәббә (әдәп фәне) жанрында, гамәли фәлсәфә буларак язылган **"ФӘВАКИҺЕЛ ҖӨЛӘСА"** хезмәтеннән өзекләр тәкъдим итәбез.

***

Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: "Өммәтемнең һәлак булмакы ике нәрсәдәдер: мал җыймакта вә гыйлем үгрәнмәенчә надан калмактадыр. Гыйлем - йозактыр, сәаль - ачкычтыр: сорашмак вә сөйләшмәк белән гыйлем ачыладыр. Берәү кечкенә чагында гыйлем үгрәнмәсә, зур булгач, алга чыкмас, ягъни гыйлем арттыра алмас. Бер ел гыйлем үгрәнмәк ике ел гыйбадәт кыйлмактан хәерлерәктер. Әдәпнең җимеше - гакылны үстерү. Гыйлемнең җимеше - изге гамәле. Бәндәгә дөньяда бирелгән нәрсәләрнең артыграгы хикмәттер вә ахирәттә рәхмәттер". Имам Хәлил әйтте: "Кайсы галимгә юлыксам да, аннан гыйлем алдым вә аңа гыйлем бирдем". Димешләрдер ки, имам Мазниның кулында имам Сибәвәйһ китабы егерме мәртәбә тузды вә ертылды, ягъни күп укыганнан вә күп истигъмаль кылганнан гыйбарәттер.

Әфләтун хәкимгә бер кеше әйтте: "Йә хәким, бу кадәр гыйлемне ничек үгрәнеп бетердең?" Әфләтун әйтте: "Тәхсил гыйлем вакытымда мин яндырган майны үлчәп карасаң, гомерем буенча эчкән нәрсәдән кубрәк яндырганмын", - диде, озак тәхсил кыйлдым, димәктер.

... Ибн Габбас радыйаллаһу ганһүдән сорадылар: "Ни-нәрсә белән син бу кадәр гыйлем дәрәҗәсенә ирештең?" - диделәр. Ибн Габбас әйтте: "Сорагучы тел белән, белгүче калеб белән вә түземле остаз белән", - диде. Бәзер Җәмһәрдән сәаль кыйлдылар: "Йә мәлик, син ни белән бу кадәр гыйлемгә ирештең?" - диделәр. Бәзер Җәмһәр әйтте: "Карга кебек иртә тордым, дуңгыз кебек комсыз булдым, эт кебек сабыр булдым, мәче кебек тәвазыгълыклы (тыйнак) булдым да, гыйлем дәрәҗәсенә васыйл булдым, максуд хәзинәләре михнәт күпере өстендәдер", – диде.

... Имам Әбү Йосыфтан бер мәсьәлә сорадылар. "Белмим", - дип җавап бирде. Әйттеләр: "Һәр көндә бәйтелмалдан (казнадан) фәлән кадәр эш хакы аласың, "белмим" дип әйтәсең", - диделәр. Әбү Йосыф әйтте: "Мин гыйлемем кадәр аламын, әгәр наданлыгым кадәр алсам иде, бөтен дөньядагы нәрсә минем эш хакыма җитмәс иде", - диде. Әбү Бәкер әл-Кабатыйдан берәү бер сүз сорады. Кабатый минбәрдә иде, "белмим" дип җавап бирде. Әйттеләр: "Бу урын белмәгәннәр урыны түгелдер", – диделәр. Кабатый әйтте: "Мин гыйлемем кадәре мендем. Әгәр наданлыгым кадәре менсәм иде, күккәчә менәр идем", - диде.



Белмәгәнеңне әйтмә, белгәнеңне фәһемлә. Әристу (Аристотель) әйтте: "Әдәпнең күркәмлеге нәсәбнең кабахәтен фазыйләт - гыйлем вә әдәп беләндер, асыл белән вә нәсәб белән түгелдер. Берәү әдәпсез булса, нәсәбе заегъ (файдасыз) булыр", - диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: "Ата балага нәрсә бирсә, биргән нәрсәсенең иң әгъләсе - әдәптер", - диде. Гали радыйаллаһу ганһү әйтте: "Адәмиләр галим яки укучылар, калганы һәмәҗ (вәхши) вә гавамдыр".

Бервакыт Васикъ биллаһ хәлифәнең остазы килде, остазын гаять гыйззәт вә икрам кыйлды. һай-һай, бәрәкаллаһ, остазыңны бик гыйзәт вә бик икрам кыйлдың, диделәр. Васикъ әйтте: "Иң әүвәл Аллаһы Тәгаләнең зикере белән минем телемне ул ачты, Ходаның рәхмәтенә якын ул кыйлды", - диде. Искәндәр әйте: "Анам мине күктән җиргә индерде, остазым җирдән күккә күтәрде". Вә дәхи Бөзерҗмәһәрдән сорадылар: "Ник бу кадәр остазыңны атаңнан да артыграк итеп тәгъзыйм кыйласың?" - диделәр. Бөзерҗмәһәр әйтте: "Атам - фани яшәешкә сәбәп. Остазым бакый яшәешкә сәбәп булды. Аның гыйлеме дәрьясыннан сугарылам, хикмәт агачыннан җимешләрен җыямын", - диде.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйтте: "Галимнәр йөзенә карамак – гыйбадәттер". Мөхәммәд бин Җәгъфәрдән бу хосуста сәаль кыйлдылар, ягъни Пәйгамбәрнең бу сүзен бәян кыйл, дип илтимас кыйлдылар. Мөхәммәд әйтте: "Галимнәр йөзенә карамак шуның өчен гыйбадәттер ки, алар сиңа ахирәт бурычларын исеңә төшерерләр", - диде. Хәлил әйтте: "Галимнең ялгышы вә хатасы тиз фаш булыр, җаһилнең ялгышы җәһаләте астында өретелмештер". Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: "Дөньяда фетнә килер, халыкны тар-мар китерер. Әмма галим котылыр".

Димешләрдер ки, малның тогъяны (бозыгы) булган кебек гыйлемнең дә тогъяны бардыр. Берәү белмәенчә гамәл кыйлса, ислах кыйлудан артыграк әфсад кыйлыр. Мәсәлдә килмештер ки, гыйлемсез гамәл кыйлган кеше юлсыз җирдән йөргән кеше белән бәрабәрдер. Бәс, гыйлем эстә, гыйбадәтеңә зарар бирмәсен, вә гыйбадәт гыйлем эстәмәкеңә зарар бирмәсен. Бер кемсәнә Пәйгамбәр галәйһиссәламгә әйтте: "Мин хәдисләр вә яхшы сүзләр ишетәмен, хәтеремнән чыгадыр", - диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: "Кулыңнан ярдәм эстә, ягъни ишеткәнеңне язып куй", - диде.

Мәсәлдә килмештер: күңелгә бикләгән качар, язып куйган карар кыйлыр. Гыйлем - аудыр, язмак - баудыр. Шәгъби әйтте: "Гыйлем бабыннан һәрни ишетерсең, язып куй, кирәк дивар үзәренә булса да", - диде. Риваять кыйлмышлардыр ки, имам Фараби хәзрәтләре тәхсиле гыйлем вакытында бик фәкыйрь иде. Кәгазь сатып алырга да акчасы юк иде. Урманга чыгып йөреп, күңеленә төшкән хикмәтләрне агач яфракларына язып йөрер иде. Кәгазь тапкач, барып күчереп алыр иде.

Гали радыйаллаһу ганһү әйтте: "Дөньяда гыйлем хисапсыз күптер, яхшырагын вә файдалырагын кабул ит", - диде. Һәрни китап кулыңа төшсә укы, яхшысы белән гамәл кыйл. Гыйлемнең ниһаяте юктыр, мең ел укысаң да, белмимнән башка булмассың, һаман гыйлемнән туймассың...

# НАМАЗ - ДИННЕҢ ТЕРӘГЕДЕР

## Йөз ел элек

Намаз калдырылса, диннең зыянлануы, хәтта егылуы ихтималдыр.

Бу мәгънәдәге сүзләр Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән төрле юллар белән риваять ителә, иснадында зәгыйфьлек булса да, мәгънәсе дөрест вә сабиттыр.

**ШӘРЕХ ВӘ АҢЛАТМА**

Намаз - исламның бөек рөкеннәренең берсе, шәһадәт вә тәүхидтән соңра, иң олуг бинасыдыр.

Намаз – бәндәнең мәгъбуденә вә Раббысына булган мөнәҗәте, үзенең бәндәлеген вә Раббысын таныган бәндә икәнен күрсәтә торган иң күркәм рәвешедер. Бәндә намазында эчен вә тышын арулап, нәҗес вә мордар нәрсәдән (шайтанга мөнәсәбәтле вә аңа сөекле шакшылардан) үзен ерак итеп, Халикы вә мәгъбуде, бар нәрсәне күрүче һәм ишетүче мәгъбуде хозурында (мәгънәви) ихтирам вә тәгзыйм рәвешләренең барын да торгыза. Куллары бәйләнеп, хөкемдар хозурына китерелгән бер җинаятьче кебек аяк өстендә тора, хәвеффеннән вә дәһшәтеннән бөгелә, аяк астына башын, иң кадерле йөзене куеп, ахырда тез чүгеп, зар вә нияз ихтияҗларын җиренә җиткерә.

Бу эшләр арасында, мөнәсиб, Аллаһка яраклы вә сөекле мөнәҗәтләрне, вә кирәгенчә мактау вә тәсбихләрне, вә Коръәндән бер кадәр аятьләрне укып, ялвара, олуг хәҗәтләрен юмарт Раббыдан тели, вә бу кадәр ялварулар белән, иманлы кеше, Раббыны таныган бәндә, әлбәттә, ләззәт таба вә ошбу рәвешне үзе өчен бәхет вә сәгадәт дип белә, Раббыннан моңа булган олуг тәүфикъ вә гыйнаят дип саный.

Бер кемсә чын иман сахибы булса (Аллаһны таныса), аның калебендә, әлбәттә, мәзкүр рәвешчә намаз укымак хисе уянса кирәк, вә аның вөҗданы аны тиеш вә таләп итсә кирәк. Бер-бер сәбәп белән тиешле вакытыннан кичексә, аның калебендә авыр җәрәхәт вә авырту туса кирәк (вөҗданы газапланса кирәк).

Кыскасы: иман намазны эсти, намаз берлә туклана вә аның белән Аллаһ хозурында кабул вә танылган була, вә аның берлә бәндәгә чын котылу бирә.

Намазсыз иман вә дин зәгыйфь, җимешсез агач, югалырга торган нәрсә, уләргә торган хаста кебидер.

Намазсыз кеше, Аллаһны чынлап танымаган, үзенең бәндә икәнен яхшылап белмәгән надан, вә һәм үзенең хәҗәтләреннән, намазда булган шәрәф вә хасиятләрдән гафил кемсәдер.

**Мелла Галимҗан БАРУДИ**
**"Дин вә әдәп", 517,518 бб. №17, 1915 ел**
**Фатих ХӘБИБ әзерләде**

# Аксакал хәзрәтебез



Элек-электән авылларда барча халыкның хөрмәтен казанган, нинди генә авырлыклар килсә дә туры юл күрсәтүче, үзенең алтыннан да кыйммәтрәк булган киңәшләрен бирүче, һәркемне кайгыртып яшәүче картларыбыз булган. Шундый аксакалыбыз, Мәсәгут авылы имамы Кәбир хәзрәткә 80 яшь тулды. Кәбир хәзрәт - хезмәт һәм тыл ветераны, егерме елга якын гомерен мәхәлләдә имам булып тора. Хәзрәт, мәхәллә имамы - халыкның рухи тәрбиячесе, мөгалиме. Бу шулкадәр изге һәм җаваплы вазыйфа, аңардан мәхәлләдә яшәүче төрле яшьтәге, төрле катлам кешеләре белән аңлашып эшләү сорала. Кәбир хәзрәт Азнакай шәһәренең Ак мәчете каршындагы башлангыч дини белем бирү мәдрәсәсендә Кәшиф хәзрәттән алган һәм Яр Чаллы шәһәре Ак мәчет мәдрәсәсендә алган тирән дини белеменә нигезләнеп, районыбызның Мәсәгут, Яхшыбай, Илбәк, Ирекле авылларында дини йолаларны үти.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримнең "Ниса" сүрәсендә (59 аять): "Ий мөэминнәр! Аллаһка итагать итегез, һәм расүлгә итагать итегез! Шулай ук үзегездә булган Коръән белән гамәл кылып, Коръән дәлилләре белән әмер итүче дини хуҗаларыгызга, имамнарыгызга итагать итегез!.." - диде. Авыл халкы хәзрәтебезне бик хөрмәт итә, шуңа күрә аны икенче , өченче срокка да зур ышаныч белән мәхәллә имамы итеп сайлый. Хәзрәт халык арасында динебезне аңлатып, Аллаһы Тәгалә кушкан фарыз гамәлләргә, гыйбадәтләргә өнди, хаталарны төзәтә, гөнаһлы эшләрдән сакланырга чакыра. Авылда Аллаh йорты булган мәчеттә вагазь һәм дини кичәләр үткәрә, гыйлем бирә, җәмәгать намазларын алып бара. Дөньяга сабый аваз салса да, яшьләр никахлашса, кардәшләребез дөньялык гомере тәмамланып вафат булса, Коръән мәҗлесләре үткәрергә ниятләсә дә, авыл халкы иң беренче Кәбир хәзрәт янына килә. Һәр гамәлен ихласлык белән, бары бер Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын өмет итеп башкара ул. Аксакал буларак үзенең диндә, дөньялыкта булган тәҗрибә-киңәшләрен мөхтәсибәткә һәм яшь буынга һәрдаим җиткереп, киңәшләшеп тора.

Районыбызның мәхәллә имамнары арасында иң өлкән һәм хөрмәтле Кәбир хәзрәтебезне ихластан мөхтәсибәтебез, авыл имамнары исеменнән туган көне белән тәбрик итәбез. Ныклы сәламәтлек, гаилә һәм балалар, оныклар бәхете, озак еллар безне сөендереп, олы киңәшчебез булып яшәвен телибез.

**Равил ДӘҮЛӘТ,
Азнакай районы**

# Мөселман егет ярышта да сынатмый ул




Күптән түгел безнең өчен бик кызыклы, алдан көтеп алган бер чара булды. Без, икенче төрле әйткәндә, җамигъ мәчетенә йөрүче төрле мәктәп балалары, вакытка турникта һәм брусьяда күтәрелү, чүгәләү, ерак арага урнаштырылган предметка атып укларны тидерү, теннис ракеткаларына куелган агач шакмакларны тизрәк йөртү, метр ярым биеклектән төшерелгән агач кубикларны тотып алу кебек уеннарда үзара җитезлектә көч сынаштык.

Хөкемдарларыбыз Камил Шәрәфетдинов белән Ринат Сабиров абыйлар алдында да сынатасы килмәде. Бар күнегүләрне дә тизрәк, матуррак һәм төгәлрәк эшләргә омтылдык. Күнекмәләр күрсәтү минутлары тәмамлангач ярышларны оештыручы абзыйлар очколарыбызны санап карадылар. 1 нче гимназиянең 6а сыйныфыннан килгән Тимербулат Мирзанов - беренче, 10 нчы мәктәпнең 6е сыйныфында укучы Дамир Кучкарев - икенче, шул ук мәктәпнең 5м сыйныфында укучы Нияз Мөбарәкҗановларның өченче урынны яулавы билгеле булды.

Ә алдан әзерләнгән агач кубиклар белән 5-8 яшьлекләр арасында оештырылган спорт уеннары тагын да кызыклырак булды. Әти-әниләре рухи көчтәвәккәллек бирүчеләр буларак карап торганлыктан, мәчеткә йөрүче нәниләре дә җан тиргә батып ярыштылар. Мин үзем дә ярышларда болай ярыйсы гына көч-җитезлек күрсәтеп, берничә бүләк-санак алдым. Иң кадерлесе - әтиемә универсаль отвертка булгандыр ул. Көнкүрештә кирәге чыгып кына тора бит...

Тагын шунысын да әйтергә онытып торам икән. Ахырдан барча әтиләр чын арбалеттан атып карадылар, төз атучыларга бүләкләр тәти торды, беркем дә буш кул белән китмәде.

Бәйгеләрнең баш хөкемдары - мәчетебезнең имамы Хәлим Шәмсетдинов әлеге уеннарга йомгак ясаганда, тәмләп кайнар чәй эчәр алдыннан тагын бер сөенечле хәбәр җиткерде бит әле. Тиздән шәһәребез читендәге наратлыкта традицион мөселман балалары Сабантуе узачак. Сер түгел, кабат көч сынашырга исәбем бар. Тик иртәнге намаздан соң саф һавага чыгып бераз максатчанрак хәрәкәтләнергә, йөгереп керергә исәбем. Бу юлы да сынатмам Аллаһы боерса!

**Булат НИГЪМӘТҖАНОВ,
Алабуга шәһәренең 10 нчы
мәктәбе укучысы**

# БЕЗДӘЙ ТАТУ МИЛЛӘТ БУЛМАС

Апрельнең бик матур көнендә Ульяновск өлкәсенең Николаевка районындагы мәчеткә никах мәҗлесенә барырга насыйп булды. Аллага шөкер мәҗлес бик матур узды, хәзрәтнең искиткеч мәгънәле вәгазе күңелнең бөтен кылларын тибрәтте. Мәчеттә эшли торган Һәва, Нәсиха ханымнар безне бик тәмле татар милли ашлары белән сыйладылар. Рәхмәтләребезгә каршы алар: "Аллаһыга шөкер, мәчетебездә еш кына никах мәҗлесләре, Коръән, Корбан ашлары, ифтар мәҗлесләре уздырыла. 200 кешелек урыныбыз, савыт-сабаларыбыз да бар. Кирәк булса зур мәҗлесләрне дә, тыйнак табыннарны да оештырырга ярдәм итәбез. Ә инде якшәмбе көннәрендә бездә дини дәресләр уздырыла. Хәзрәтебез безне Коръән укырга өйрәтә. Инде Изге китапны кулыбызга тотып, әкрен генә укый да башладык", - диделәр.

Бу сүзләрне ишеткәч, бик шатландык, чөнки Николаевка районында гомер-гомергә рус, татар, мордва халыклары дус-тату гомер кичереп, руслар һәм мордвалар үзләренең дини бәйрәмнәрен чиркәүләренә барып үткәрә алсалар да, безнең халыкның моңа кадәр андый мөмкинлеге булмады - мәчет төзергә рөхсәт тә, акча да юк иде. Ә бүген Аллаһыга шөкер, мәчет ишекләре һәрвакыт ачык, манарасы әллә кайдан балкып күренеп тора!

Менә шул изге эшне - мәчетне төзүне оештырган, финанслаган, хәл кадәренчә ярдәмен күрсәткән барлык кешеләргә АллаһыТәгалә ике дөнья бәхетен күрергә насыйп итсә иде. Изгелек юлындагы һәр адымнары меңләтә савап булып кайтса иде.

Әйе, бу зур эш бер дә проблемасыз гына булмый инде. Төзелеш вакытында пластик тәрәзәләргә ташлап атып ватучылар, мәчет территориясенә дуңгыз башы ташлап китүче кешеләр дә булды. Бүгенге көндә дә азанны җомга көннәрендә генә әйтергә рөхсәт бар... Әле башкарасы эшләр шактый. Иң мөһиме - халык йөрсен иде мәчеткә. Җәмәгать белән укылган намаз ялгыз укылган намазга караганда 25 мәртәбә саваплырак, диелгән бит. Әгәр шәригать кушканча җәмәгать намазларыннан калмыйча һәрвакыт бергә җыелып, матур итеп сәлам бирешеп, хәл-әхвәл белешеп яшәсәк, безнең кебек бердәм, тату һичбер милләт булмас иде.

**Гөлфия ТАҖИЕВА, Казан**

# Никах укырга мулла юк, сәдака бирер кеше юк...



Җиңү көне илебез, халкыбыз өчен зур бәйрәм, чөнки бездә сугыш фаҗигасе кагылмаган бер генә гаилә дә юк. Сугышның ачы хәсрәтен күргән, илебез тынычлыгы өчен, туган җиребезнең һәр карыш җире өчен гомерләрен дә кызганмыйча сугышкан ветераннарыбыз сафы елдан-ел сирәгәя бара...

Җиңү бәйрәме тантанасына Сахалиннан ук килгән ветеран милләттәшләребез яныннан тыныч кына узып китә алмадым. Алар минем белән рәхәтләнеп үз телебездә сөйләштеләр. Нәҗип абый Рәхимуллин, Разия апа Адилова, Хәербәнат апа Бикчәнтәева, Сания апа Атинбаева һәм сугыш чоры баласы Гөлсадә апа Рәхмәтуллиналар - барысы да чыгышлары белән Татарстаннан икән. Кайсы Казаннан, Арча ягыннан, Түбән Камадан… Үз вакытында алар вербовка белән Сахалинга киткән булганнар. Телләрен саклап кала алсалар да, динебезне саклап, балаларына, оныкларына тапшыра алмаганнар. Һәрберсенең телендә бер сүз: дин бетте бездә!

Казанда аларның нинди хисләр кичерүен мин гөманлый гына алам. Монда телебез, гореф-гадәтләребез саклана, чөнки динебез исән, ул елдан-ел ныгый бара, мәчетләребез гөрләп эшләп тора. Ә аларда бер генә мәчет тә юк икән! Балага исем кушарга, никах укырга мулла юк, мәет юырга кеше юк, хәтта сәдака бирергә дә кеше калмады, диләр. Коръән укытырга кирәк булганда үзбәкләрне, кыргызларны чакыралар икән. Мәетләрне русларча табутларга салып җирли башлаганнар. Элек ул якларда 20 мең чамасы татар яшәгән булса, хәзер 5 меңләп кенә калган.

... Сахалин ветераннары белән аралашкач, күңелгә бик авыр булып китте. Халкыбыз патша заманасында сөргеннәргә сөрелсә дә, чит илләргә чыгып качса да үзенең телен, гореф-гадәтләрен онытмыйча, милләт булып сакланып калган. Диннәрен ташламаган шул алар...

**Илсөяр ГАБИТОВА,
Казан**

# КЕШЕ ҖИРГӘ КИТӘР ҺӘМ КАЛДЫРЫР

***"Әдәбият елын без Мәдәният елының дәвамы буларак кабул иттек. Димәк, бу елда безнең эш-гамәлләребез тагы да үтемлерәк һәм нәтиҗәлерәк булырга тиеш. Әдәбият елы - язучылар, журналистлар, ягъни иҗат белән шөгыльләнүчеләр өчен генә түгел, ә бәлки бөтен халык өчен кирәк. Әдәбият халык өчен языла, театрларыбыз халык өчен эшли", - дигән иде ТР Дәүләт Советы депутаты, шагыйрь Разил Вәлиев Intertat электрон газетасына биргән интервьюсында. Шулай ук ул яшь язучыларга да игътибарны арттырырга җыенулары турында әйтте...***

***Игътибар дигәннән, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте әдәбиятка - яшь язучылар, шагыйрьләр иҗатына беркайчан да битараф булмады, гел күзәтеп, төрле бәйгеләр, очрашулар уздырып килде. Әдәбият елындагы беренче очрашуыбызны без Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллинның хәер фатихасы белән Казан (дәүләт) федераль университетының "Әллүки" иҗат берләшмәсенә йөрүче яшь талантлар, Татарстан җөмһүрияте Язучылар берлегенең яшь язучылары белән оештырдык. "Коръән һәм әдәбият" дип аталган очрашуга Диния нәзарәтенең дәгъват бүлеге җитәкчесе, әдәбият дөньясыннан искиткеч хәбәрдар Нияз хәзрәт Сабиров; җәмәгать эшлеклесе, язучы Рабит Батулла һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, шагыйрь Рәмис Аймәт, "Әллүки" әдәби-иҗат берләшмәсе кураторы Халисә Ширмәннәр чакырулы иде.***

***Очрашуга шактый яшьләр җыелды, дини мотивлар белән әсәрләр иҗат итүче талантлы яшьләр бездә шактый икән. Аларның кайберләре Язучылар берлеге әгъзасы булып тора, кайберләре менә-менә җыентыгы басылып чыкканын көтә.***

***Очрашу Нияз хәзрәт Сабиров чыгышы белән башланып китте, Коръәни Кәрим аятьләрен укыганнан соң, ул яшьләргә төрки әдәбиятның башлангычы, тамырлары турында тәфсилләп сөйләп бирде. Әдәбият тарихының һәр чорына тукталып, шул чор әдипләренең иҗат юлы, шәхес буларак мөселман дөньясына керткән өлешләре турында бәян итте. Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Суфый Аллаһияр, Мәүлә Колый, Габдрахман Утыз-Имәни кебек бөек шәхесләребез, аларның әсәрләрендә күтәрелгән проблемалар, бу проблемаларның бүгенге көндә яңгырашы турында бер очрашуда гына сөйләп бетерү мөмкин түгел. Ун гасыр эчендә тупланган нинди бай әдәбиятыбыз - олы мирасыбыз бар бит безнең...***

***Әйе, борынгы чор әдипләре һәрберсе динне белгән, шәригать кануннарын белгән, әсәрләрендә халыкны шул кануннарга буйсынып яшәргә өндәгән... Бүгенге талантлы яшьләребез арасында да шәригать кануннары турында, дөньяда яшәүнең мәгънәсе турында тирән эчтәлекле шигырьләр язган егет һәм кызларыбыз бар, шөкер. Шулай итеп, Мәхмүт Кашгарыйлардан башланган әдәби мирас бүгенге көндә дә актуаль, бүгенге көндә дә яшьләребез әдипләребезнең иҗатын өйрәнә, кызыксына һәм үзләре дә шактый үзенчәлекле әсәрләр иҗат итә.***

*Айгөл БИКТИМЕРОВА,*
*Диния нәзарәтенең яшьләр эшләре бүлеге җитәкчесе*



*Алсу НУРГАТИНА*

***

Яулыгыма каршы төште әни...
Әрәм була балам, яшьлегең.
Башыңдагы яулык чикләр барысын,
Эләр күңелеңә нәс-йөген.

Фарыз икән, намаз-уразасын,
Үз вакыты җиткәч үтәрсең.
...Белсәң иде, әни, кемнең, кайчан
Нинди халәтләрдә китәсен!..

Чикләмәде яулык күңелемне,
Сансыз, юк уйларны ташладым.
Моңа кадәр мин бар идем генә,
Яулык кигәч яши башладым...

Сәҗдә микән.. Дога микән әллә
Бикле йөрәкләрне саф иткән?!
Булмасын ул киләчәк казасы,
Сиңа намаз укыр көн җиткән!

Якын диеп йөргән дусларымны,
Яулык кигән көнем урлады.
Янәшәмдә калды тик ихласлар,
Яулык почмагына уралып.

## ӘЙЛӘНӘ ҖИР...

Әллә ничек кенә,
Әллә ничек соңгы көннәрдә,
Күңелемдә йөрткән уйланулар,
Сагыш булып тула күзләргә.

Бәхет табам диеп җанын ерта,
Максатына җитсә аз гына,
Күңел үсә,
Әллә нишли күңел,
Намазлар казага калына...

Без бит шундый,
Әллә ниндиләр без,
Баксаң бит гап-гади дөньябыз.
Гөнаһ төшә. Тәүбә кала, аннан

Күзләр ертып яшьләр коябыз...
Гомер исә кулларыбыз ирке,
Һәр гамәлгә сыйган бер хикмәт...
...Догаларны барлыйм кем булсам да,
Шунда ята безнең хакыйкать.

*Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ*

## ТОРМЫШ ӘЛЕ ДӘВАМ ИТӘ

Кеше җиргә китәр өчен килә...
Һәм калдырыр өчен мирасын.
Кайчан да бер барыбыз бу җирдә
Ашламалы туфрак буласы...

Ашлап китәрбезме бу җиһанны?
Бәлки, бары ташлап китәрбез...
Сандыгыбыз ниләр белән тулыр?
Киләчәккә ниләр илтәрбез?

Олы яшькә җиту – бәхет эше.
Кайсыбызга язган ничаклы?
Беребез дә белми кайчанлыгын
Кинәт сүнәчәген учакның...

Һәм без җирдә бары кунак кына...
Һәм без бары Хакның коллары.
Тик яшибез нәфес колы булып
Кайчагында җирдә, нибары...



Хуҗа түгелләрне "хуҗа" итеп
Баш иябез кайчак эткә дә.
Көнебезне гафиллеккә биреп,
"Төзәлербез, – дибез, – иртәгә!"

Кайсыбызга кабат таңнар туа,
Яңа форсат туа тәүбәгә.
Тик "Рәхмәтләр" ява Аны онытып,
Үзе дә кол булган бәндәгә...

Маңгай тирләренә бата-чума
Ярыйбыз ла әллә кемнәргә..
Байлык, зиннәтләрдә коенсак та
Онытыла зәкят түләргә.

Ә кемнәрдер зур байлыклар туплый,
Ел да бара әллә кайларга.
Тик оныта, яки кирәксенми
Изге сәфәр – хаҗын җайларга.

Аллаһ биргән сый-нигъмәтләр белән
Көн дә ризыкланып торсак та,
Тыелмыйбыз Аллаһ тыйганнардан –
Нәҗес, хәмер, хәрам корсакта...

Тәүлектәге вакыт өлешләрен
Йокы, телевизор, эш ала.
Бер Аллаһка сәҗдә өчен генә
Вакыт җитми кала, югала...

Ник бу җиргә килгәнлеген кеше
Йә оныта, яки уйламый.
Җирдә тормыш шулай дәвам итә –
Көн дә бәйрәм, көн дә аулагөй...

Әмма килер бер көн: һәммәбезгә
Булыр ул көн җавап тотасы!
Тормыш әле шулай дәвам итә,
Кем оттырыр, кемгә отасы?!

## ҖЕНАЗА

Манаралар калкып дәшеп тора...
Яңгыратып күкләр пәрдәсен,
Мөәзин азан әйтә...
Шул мизгелдә
Тын калмыйча ничек түзәрсең?

Азан белән намаз арасымы –
Яшәү белән үлем арасы?
Мәрхүмнәрне искә алган чакта,
Нәкъ шулай ук тынып каласың...

Мизгел генә бары,
Берни түгел.
Бөтен гомер бары бер мизгел!
Күкне ярып азан ишетелә:
Соклана да, сыктый да күңел...
Соклана да күңел, тетрәнә дә:
Гавәм соңарттыры намазга...
Дөнья куып - дөнья куйды берәү,
Намазлары мәңге казада...

Соңгы намаз.
Соңгы тәкбир.
Тынлык...
Яшь тыгыла килеп бугазга.
Алда ләхет ята.
Ул – намазсыз.
Һәм укыла аңа җеназа.

## ГӨНАҺ ИЛӘ ТӘҮБӘ

1

Гөнаһ кылу башта коточарлык
Авыр зур йөк булып тоела.
Хаталанган саен ул йөк бушый,
Җиңеләя бара, җуела.

Шулай итеп "тырыша торгач" бер көн
Сизелми дә башлый авырлык.
Җиңеләйгән саен өелә тора
Гөнаһ арты гөнаһ тау булып.

2

Мин тәүбәгә киләм таң атканда,
Кичен тәүбәләрем бозыла:
Гомер җепләрендә тәсбих булып
Гөнаһ катыш тәүбә сузыла...

Мәхәббәт һәм нәфрәт арасыдай
Якын гөнаһ-тәүбә арасы:
Тәүбә кылсан иске хаталардан
Кабат туып тора яңасы...

3

Ялгыш адым сөйри җәһәннәмгә,
Тәүбәләрем – тартып чыгара:
Тәүбә арты – гөнаһ, кабат тәүбә... –
Җан шайтанга шулай олага!

"Күңел – шайтан!" – диләр,
күңел зәгыйфь!
Мин гөнаһлы адәм баласы:
Ә шулай да, җәһәннәмгә түгел,
Җәннәтләргә килә барасы!

# ӨЧЕН КИЛӘ... ӨЧЕН МИРАСЫН



Айдар ҖӘМАЛ

Нәрсә соң ул мәңгелек? –
Аллаһ язган бер мизгел.
Күчсен иде мәңгелектән
Мәңгелеккә хәр күңел.

***

Салават күперенә
Сокландым.
Дога күпере бит ул –
Уйландым...



Дания НӘГЫЙМУЛЛИНА

## БҮЛӘК

Безгә Ходай сызлануны биргән,
Сагынуны мулдан яралткан.
Йолдызларга юлламасын бирә,
Чын күңелдән әгәр яратсам.

Ашкынуны ялгышуга бәйләп,
Ходай безгә сынау юллаган.
Яшәү серен өлгермичә аңлап,
Азмы кеше үзенә кул салган?!

Безгә Ходай вөҗдан газабын да
Арбабызга төяп җибәргән.
Үкенүне кеше танымаса,
Көнкүрештән безнең китәр ямь.

Караңгылык чолгап алса гына,
Күпләр аңлый кояш кадерен.
Ходай безгә авырлыклар биргән,
Без күтәрә алган кадәрен!

* * *

Ташлы юлдан үткән арбаң
Тәгәрмәче какшаган.
Гамәлләрең бәллүр гөлгә,
Көйсез җырга охшаган.

Мәшәкатьләр маңгаеңа
Сызган тирән буразна.
Азан тарта итәгеңнән:
"Туктап тор", – дип беразга.

Өстеңдә затлы кием, тик
Намус сорый ямаулык.
Тәнгә генә түгел икән,
Җанга да кирәк саулык!

Тормыш киштә, баскыч төсле,
Аста – сораучы хәер.
Мохтаҗларга күзең йомып
Эчәсең һаман хәмер.

Кылган эшләрең – җир җиләк,
Ул яртылаш черегән.
Акча – байлык дип санийсың,
Ялгышасың, чир икән.

## ГАЙБӘТ СӨЙЛӘҮ

Елан агуыдай тып-тып
Касәгә гайбәт тама.
Гайбәт – фәрештәләр тоткан
Дәфтәрдә кара тамга.

Гайбәт сүзне бизәсә дә,
Төссезли киләчәкне.
Гайбәт сөйләү – өзгән төсле
Күңелдәге чәчәкне.

## ӘНИ ДОГАСЫ

Имтихан бирергә керәсең –
Әниең гел сиңа догада!
Яныңа фәрештә күк оча
Кояшка ияреп тора да.

Җан сызлый. Әниең синнән дә
Катырак сызлана. Күр әнә
Нилләрдер пышылдый. Ул тагын
Сиңа дип бер дога өйрәнә.

Эшләрең уң булды. Үзең дә
Ышана алмыйча торасың.
Әниең юллады сиңа дип
Эчкерсез шифалы догасын.

Әниең авырды. Хәлләрен
Син кайтып белешә алмадың.
Хәтта ул чакта да әниең
Укыган догадан калмадың!

## ГӨНАҺЛЫ ҖИҺАН

Мин гаҗәпкә калмам кебек, әгәр
Җир әйләнеп беркөн туктаса,
Кылган гөнаһларны кичер(ә) алмый
Язмыш таяклары тукмаса.

Гаҗәпләнмәм, кояш чыкмый гына
Оятыннан торса кызарып,
Җиһан тулы нәфрәтләрдән өркеп,
Бәби туса әгәр соңарып.

Тәнен сатканнарга ачу итеп,
Күкләр меңгә әгәр ярылса,
Сәерсенмәм. Адым саен сүгенү
Тузан булып җанга сарыла.

Кара туфрак кардәш-туганнарның
Күп сеңдергән садә каннарын.
"Кичер безне," – диеп әби сала
Мәчетләргә сәдакаларын.

## РӘХМӘТ, РАББЫМ!

Күңел пәрдәләрен ачкан өчен,
Кояш керсен диеп, и Раббым,
Рәхмәт Сиңа! Сагышлары белән
Мин тормышны ихлас яраттым!

Һәм яратам! Кан тамыры буйлап
Аллаһ исеме җитә йөрәккә.
Ахыр чиктә Сиңа илтә юллар,
Кайсы сукмакларда йөрсәк тә.

Мине кеше итеп яратканга
Рәхмәт әйтәм Сиңа сәҗдә китеп.
Актык сулышыма кадәр, Раббым,
Саклап калсаң иде Кеше итеп...
Кеше итеп!



Рифат СӘЛАХ

## ГЫЙБАДӘТ

Аллаһ исме белән башлыйм әле! –
Изге эшләр шулай башлана
Һәм күкләргә багып дога кылам:
"Йә, Ходаем, үзең ташлама!"

Һәм диварга килеп башны куям,
Кулны куям дивар өстенә.
Бер үрмәкүч пәрәвезен үргән –
Язып куйган сыман "бисмиллаһ".

Маңгаемны җир өстенә куям
Һәм ялварып сорыйм, тезләнәм.
Мин булмасам иде язмышымның
Бәхет-сынавына түзмәгән.

Һәм күкләргә багып дога кылам,
Йә, Ходаем, үзең ташлама!
...Гаҗәпләнәм, әле шуннан соң да
Бәгыремдә күпме таш кала.

***

Җир йөзендә гомер сөргән
Күпме бөек шәхес.
Тик күбесен тоткын иткән
Ялган, гөнаһ, нәфес.

Җир йөзендә патшалар да,
Фәкыйрьләр дә кунак.
Кемгә – ерак, кемгә – якын
Нәфес, ялган, гөнаһ.

Тарих томы битләрендә
Кульязмалар калган:
Дөнья – җәннәт түгел,
Дөнья –
Гөнаһ, нәфес, ялган.

## ГАЕТ

Бу җирдә динилек буласын
Оныттык без, әллә белмәдек.
Мөэминнәр яхшыга юрасын
Хәерле булсын дип бу гает.

Мәчеттә урын юк – шау халык,
Мәҗбүрмен урамга чыгарга.
Гаеттә мәчеттән чыксам да,
Йә, Раббым, иманнан чыгарма!

Хаталы укысак намазны,
Ходаем, гафу ит, син, кичер.
Казасыз калмабыз,
Газаптан коткарчы
Иманга сусаган җан өчен.

Исламның яңадан калкуы,
Юл да юк – шау халык урамда.
Елына ике кат булса да
Кайтабыз икән бит иманга.

Бу җирнең иманлы буласын
Белмәдек бугай шул, белмәдек.
Болытлар яхшыга юрасын,
Үткәч тә, сүнмәсен бу гает.

Мәчеттән чыгабыз, һәркемнең
Күзләре яңгырга чылана...
Гаеттән чыксак та,
Йә, Раббым,
Күңелдән иманны чыгарма!

## И АЛЛАҺЫМ!..

И Аллаһым!
Кичер мине, кичер.
Догаларым кабул кылсаң икән!
Аз ялвардым сиңа.
Артык иртә
Китәм бугай Рәхмәт үзәненнән.

Иртә китәм.
Әйе, артык иртә.
Кылып бетмәс инде бөтен догам.
Күңелемә ут бир, ләкин сакла
Йә, Ходаем, тәмуг утларыннан!

И Аллаһым!
Тагын бер кат кичер
Бәрәкәтле утмәсә бу көнем.
Әгәр әмер итсәң
Гарәфәнең
Үзәнендә мәңге калыр идем.

Иртә әле,
Әйе, бөтен догам
Өзелмәдә әле үзәгемнән.
Мәңгелеккә диеп саубуллашып
Китә алмам Рәхмәт үзәненнән!

## ПӘЙГАМБӘРГӘ

Хакыйкатькә һәрчак каршы гавам,
Хакыйкатька куеп авызлык
Күп кешеләр яшәмәкче була
Эстәп ләззәт, кылып явызлык.

Үз-үзләрен илаһ итеп тоеп
Яшәп яткан чакта адәмнәр.
Син тугансың, газиз расулуллаһ,
Аллаһыдан килгән пәйгамбәр.

Үз кавемең сиңа Әмин дигән,
Аннан мәҗнүн диеп атаган.
Дошмандыр шул, итагатьле булып,
Куркып яшәүчеләр Алладан.

"Үтерергә!" - дигән Иблис үзе,
Кылыч биргән кырык егеткә.
Аллаһ кушса,
Сиңа зыян тими,
Дошманнарың сине күреп тә.

Син җиңгәнсең!
Кылыч белән түгел,
Хакыйкать һәм тугры дин белән.
...Исемеңне искә алган саен
Күз яшьләре чыга... күңелдән.

# БУЛГАННАН БАР ДА БУЛА

**Питрәч районы, Шәле авылының имамы хаҗи Габделхак Габделкаюм углы Бикмуратов 1927 елның гынварында Питрәч районы Шәле авылында икенче бала булып дөньяга килгән. Әтисе Габделкаюм абзый балта остасы булган, әнисе Мәликә апа Коръәнне бик шәп укыган.**



Әти-әнисенең менә шушы һөнәрләре Габделхак хәзрәткә дә күчкән. Кечкенә чагында кеше рәсемнәре ясап диварларга ябыштыра торган була. Әнисе, кеше рәсемнәре ясарга ярамый – гөнаһ, дип әрли. Шуннан ул дөньяда нинди күркәм әйбер бар - шуларны рәсемгә төшерә башлый. Өйләренең ян тәрәзәсеннән авыл тегермәне күренеп тора - шуны ясый. Ике катлы агач мәктәп бинасын да кәгазьгә төшерә.

Сугыш башланганда Габделхакка 14 яшь була. Ишле балалы гаилә бик ачлык күргән. Сугыш беткәч, Габделхакны Кемерово өлкәсенә хезмәт колониясенә җибәрәләр. “Аннан отпускыга безне киптереп кайтардылар”, – дип искә ала хәзрәт ул елларны. Яңадан колониягә бармаган өчен аны 4 айга Раифа монастырендагы балалар колониясенә утырталар. 1951 елда авылына әйләнеп кайткач, ул Разия исемле кызга өйләнә.

– Ишәйдек – Мансур углым туды, гаиләне туйдырырга акча кирәк иде, эш барын бар - ә акча түләмиләр. Булган акчаларыбызны җыеп, эш кораллары сатып алдык, үзем корган верстакта догалар (шәмаилләр) рамы ясый башладым, - дип сөйли Габделхак хәзрәт бу эшкә тотыну тарихы турында. - Кибеттә пыяла юк, акча да юк. Колхоз фермасына менеп, ватык тәрәзәләрнең пыялаларын алып төшеп, кисәкләргә кисеп куя идем. Язар өчен буяулар да кирәк, хатыным Разия кайдандыр битум алып кайтты, аны бензинда эретеп буяуга әйләндердек, төсле майлы буяуларны Казаннан сатып алып кайта иде. Коръән аятьләре пыялага дөрес төшсен өчен башта кәгазьдән трафаретлар ясыйм. Пыялага бронза, көмеш төсле буяулар белән язам да буявы кипкәч, битум белән буяп-каплап куям, кайсы урында төсле фольга да кулланам. Кешенең күңеленә хуш килсен, Коръән аятьләре аңлаешлы булсын дип шәмаилләремдә мәчет, табигать рәсемнәре ясый идем. Кемдер миңа пальма агачы рәсеме алып кайтып бирде, аны да пыялага төшерә башладым. Акча булмаганда шул шәмаилләрне сатып, шуның белән көн күрдек. Күбесен бушка да өләштем.

Соңрак, инструментлар күбәйгәч, башка авылларга йорт салырга йөри башладым. Яңа йортның хуҗалары догалыкларны сатып алмасмы дип үзем белән алып бара торган идем. Кайвакыт: “Ул шәмаилләрне кая куялар соң?” – дип сорыйлар иде. Ул вакытта дин тотучылар аз, халык гарәпчә белми, өйрәнмәгән. Мин ярый әнидән өйрәнеп калдым, күбесен аңлатырга тырыша идем. Менә шул вакытта вәгазьләр сөйләп, Гает намазларын укып йөргәнгәдер инде (мәчетләр юк иде әле, кеше өендә җыелышып укыйбыз), имамыбыз картайгач, мине имамлыкка кыстый башладылар. Булдыра алмам, миннән олылар бар, дип каршы килеп карасам да, 1982 елның 6 апрелендә җомга көнне, кискен генә “син буласың” дип картлар сайлап та куйдылар үземне. Мәет җирләү, балага исем кушу, никах уку – барлык вазифа минем өскә йөкләнде. Шәмаилләрне азрак ясый башладым, соңрак бөтенләй дә ясаудан туктадым.

Без, җомга намазларын, Гаетләрне йорттан-йортка күчеп йөреп укый идек, дидем бит, ул вакытта заманы шундый. Шулай күчеп йөри торгач, 1991 елда районның главасы рөхсәте белән намазларыбызны иске 1810 елгы мәчет бинасында укыта башладым. Ә 2000 елда яңа мәчеткә нигез салдык, стеналарын күтәрүдә мәктәп балалары да бик булышты. Соңрак иске мәчет янына авылыбыз егете агач мәчет салдырды, шулай итеп, авылыбызда хәзер ике мәчет бар. Аллаһка шөкер, дин куәтле, җомга намазларына, Гает намазларына яшьләр дә, олылар да бик күп йөри. 2010 елда авыру сәбәпле имам вазифасын үземнән төшердем...

Габделхак хәзрәт хатыны Разия ханым 1 малай 3 кыз тәрбияләп үстерделәр, аларның 8 оныгы һәм 2 оныкчыгы бар. Бер-берсен хөрмәтләп, яратып, инде менә 64 ел бергә, тату-матур гомер кичерәләр.

# КАЗАННЫҢ ИМАН ЙОРТЛАРЫ ХАКЫНДА БЕЛЕШМӘЛЕК НӘШЕР ИТЕЛДЕ

**Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан урта мөселман мәдрәсәсе җитәкчесе, мөхтәрәм дин әһеле һәм мөгаллим, Казанның Ал мәчете имам-хатыйбы Ильяс хәзрәт Җиһаншин бер төркем хәзрәтләргә, җәмәгать эшлеклеләренә яңа җыентык тәкъдим итте.**




“Казан шәһәренең Идел буе һәм Вахитов районнарындагы мәчетләр турында белешмәлек”нең яңа тулыландырылган басмасы дөнья күрде. Бу басмада совет чорында дин кыйммәтләрен җиткергән имамнарыбызның шәҗәрәләре, фотолары да урын алган. Яңа татар бистәсе зираты картасы һәм анда җирләнгән дин әһелләре, татар зыялылары хакындагы мәгълүмат та бар.

Белешмәлеккә ике райондагы 29 мәчет һәм 4 дини уку йорты турында мәгълүмат тупланган.

## “ТАТАР СҮЗЕ” МОБИЛЬ КУШЫМТАСЫ – IOS ПЛАТФОРМАСЫНДА

**“ТАТАР” СҮЗЕ”** дип аталган махсус мобиль кушымта эшли башлады. Моңа кадәр ул бары Android җайланмалары өчен генә иде, ә хәзер OIS кулланучылар да аны үзләренә урнаштыра ала. ТР МДН тарафыннан эшләнгән бу кушымта кулланучыларны иске татар сүзләре белән таныштыра. Һәр көн автоматик рәвештә сезнең телефоныгызга яңа сүз килә һәм аңа кыскача аңлатма бирелә, русча тәрҗемәсе күрсәтелә, Коръән һәм хәдисләрдә кулланылышы да языла. Шунысы мөһим, кушымта телефон интернет челтәренә тоташмаганда да эшли. Аны сез “Play Маркет”та таба аласыз.




# Казан өчен июнь аена намаз вакытлары

| Көн | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Өйлә Намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы ифтар | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.06.2015 | 01:07 | 01:37 | 03:07 | 12:00 | 17:23 | 20:15 | 21:45 |
| 02.06.2015 | 01:06 | 01:36 | 03:06 | 12:00 | 17:24 | 20:17 | 21:47 |
| 03.06.2015 | 01:05 | 01:35 | 03:05 | 12:00 | 17:25 | 20:18 | 21:48 |
| 04.06.2015 | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 12:00 | 17:25 | 20:19 | 21:49 |
| 05.06.2015 | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 12:00 | 17:26 | 20:21 | 21:51 |
| 06.06.2015 | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 12:00 | 17:27 | 20:22 | 21:52 |
| 07.06.2015 | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 12:00 | 17:27 | 20:23 | 21:53 |
| 08.06.2015 | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 12:00 | 17:28 | 20:24 | 21:54 |
| 09.06.2015 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:29 | 20:25 | 21:55 |
| 10.06.2015 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:29 | 20:26 | 21:56 |
| 11.06.2015 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:30 | 20:27 | 21:57 |
| 12.06.2015 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:30 | 20:27 | 21:57 |
| 13.06.2015 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:31 | 20:28 | 21:58 |
| 14.06.2015 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:31 | 20:29 | 21:59 |
| 15.06.2015 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:32 | 20:29 | 21:59 |
| 16.06.2015 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:32 | 20:30 | 22:00 |
| 17.06.2015 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:32 | 20:30 | 22:00 |
| 18.06.2015 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 |
| 19.06.2015 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 |
| 20.06.2015 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 |
| 21.06.2015 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 |
| 22.06.2015 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 23.06.2015 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 24.06.2015 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 25.06.2015 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 26.06.2015 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 27.06.2015 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 28.06.2015 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 29.06.2015 | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |
| 30.06.2015 | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |

# БАЛТАЧТА МӨСЕЛМАН БАЛАЛАРЫ САБАН ТУЕ УЗДЫРЫЛА

**26 июльдә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Балтач районы мөхтәсибәте Россиякүләм балалар Сабан туен уздыра.**



Балтачта мөселман балаларын җыеп, шушылай күркәм бер чара уздыру традициягә әверелде. Сабантуй быел Балтач районы Бөрбаш авылында сигезенче тапкыр үткәрелә. Узган елларда әлеге күркәм чарада республиканың төрле мөхтәсибәтләреннән һәм төбәкләрдән җыелган меңләгән балалар катнашты. “Безгә мөселманнар гаиләләре белән Башкортстан, Ульян, Чувашия, Марий Элдан һәм башка төбәкләрдән киләләр. Сабантуйда балалар өчен төрле-төрле уеннар, ярышлар оештыру каралган. Дүрт үлчәүдә көрәш уздырыла. Абсолют батырга скутер мотоциклы бүләк ителәчәк”, - диде Балтач имаммөхтәсибе, баш казый Җәлил хәзрәт Фазлыев.

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**

Дин вә Мәгыйшәт
*Май саны, № 5 (238)*

**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Гүзәл МИҢНУЛЛИНА
**Корректор:** Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:** *420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27/*
**Электрон адрес:** *naubahar67@list.ru.*
**Телефон:** *+7 950 326 38 36*

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе* ***Камил СӘМИГУЛЛИН****;*
*"Хузур" нәшрият йорты директоры* ***Ришат ХӘМИДУЛЛИН****;*
*ТҖМДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе* ***Нияз САБИРОВ****;*
*Татарстанның баш казые* ***Җәлил ФАЗЛЫЕВ****;*
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе* ***Габдулла ӘДҺӘМОВ****.*

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин**

**Гамәлгә куючы:** *Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).*
**Нәшир:** *"Хузур" нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в)*

*Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.*
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета **"Татмедиа" ААҖ филиалы - "Идел-Пресс"** полиграфия-нәшрият комплексында басылды *(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2).*
**Тираж: 5 мең данә** Заказ **№ 9055**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - **6 сум.**
График буенча бу санга **22 нчы май** көнне **20.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде.
Кул куелды: **19.00 сәгатьтә.**